Татар
КИТАБЫ
Татарская
КНИГА

Җиздән ясалган кара савыты.
XIX гас. ТР ММ
Чернильница.
Латунь.
XIX в. НМ РТ

Татар КИТАБЫ

Татарская КНИГА



КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2013

КАЗАНЬ
ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО
2013

ХАЛКЫБЫЗНЫҢ РУХИ ЮЛБАШЧЫСЫ

Төрки-татарлар безнең эрага кадәрге чордан алып хәзерге көнгә кадәр рун язуы, уйгур, гарәп, латин алфавитларын һәм кириллицаны кулланганнар. Язулы булу – мәгълүматлылык дигән сүз, ә мәгълүмат зур мәдәни көчкә ия. Китап күп гасырлар дәвамында төп һәм бердәнбер мәгълүмат чарасы булган. Татар мәдәнияте тарихында да ул мәртәбәле урын алып тора.

Халкыбызның борынгыдан ук китаплы халык булуы ислам дине белән бәйле. Ислам динендә «Китап» атамасы Изге Коръән китабы дигәнне белдергән. Мөселманнар буларак, татарлар да, Китап дигәндә, иң беренче нәүбәттә, Коръәнне күздә тотканнар. Коръән сүзе, ягъни Китап сүзе, халкыбыз өчен иң газиз һәм мәртәбәле дәлил буларак кабул ителгән. Гыйлемгә, укуга, Китапка сак мөнәсәбәт һәм тирән хөрмәт ислам диненең нигезенә үк салынган. Пәйгамбәрнең күп хәдисләрендә гыйлем олыланган.

Тарихтан күренгәнчә, «Белем алу һәр мөселман кешесенә фарыз» дигән хәдискә татарлар аеруча тугрылыклы булырга омтылганнар. Татарлар арасында белем алуга, укуга карата гасырлар буе шундый мөнәсәбәт яшәп килгән. Нәтиҗәдә татар халкының милли хасиятләре, ислам тәгълиматы белән аерылгысыз бербөтен рәвештә тыгыз бәйләнеп, халкыбызны иманлы һәм динле, мәгълүматлы һәм мәгърифәтле иткән. Кайда гына яшәсәләр дә, татарлар мәчет төзергә, мәктәп-мәдрәсә ачарга, матбугат һәм китапчылык эшен гамәлгә куярга тырышканнар. Татар халкының аң-белемгә, китапка багышланган мәкаль һәм әйтемнәре, төрле дәвер әдипләренең шигырьләре һәм тирән мәгънәле канатлы сүзләре Китапны изгеләштергән.

Китапның төп асылын халыкның язуга ия булуы тәэмин итә. Идел-Урал буйларында яшәгән борынгы бабаларыбыз ислам дине белән бергә гарәп язуын да кабул итеп, халкыбыз бу язуны мең елдан артык кулланган. Гарәп язулы китаплар татарларның җанына ук изгелек күзәнәкләре кебек үрелгән.

Китапчылык үсеш алсын өчен тагын бер мөһим шарт – халыкта язма һәм басма сүзгә ихтыяҗ булу, аң-белемгә омтылышның югары дәрәҗәгә җитешүе, белем-уку йортларының үсеш алуы.

Кулъязма китап

Төрки-татар телендәге беренче дәвер борынгы китаплар гарәп хәрефләре белән язылган. Ягъни кулдан күчерелгән китаплар кулланылышка кергән.

Татар кулъязма китабының мең елдан артык тарихы бар, дип хаклы рәвештә әйтә алабыз. Чөнки Идел-Урал буйларына гарәп язуы үтеп кергәч тә, Коръән һәм башка дини китапларны күчереп язу, шул рәвешчә тарату, мәктәпләр өчен дәреслек-кулланмалар булдыру тормышка ашырыла башлаган. Гарәп язуы һәм гарәп теле мөселман төрки-татарларның рухи тормышында озак дәверләр мәртәбәле урын биләп килгән.

Татар кулъязма китабы тарихын тирәнтен өйрәнгән галим, академик, тарих фәннәре докторы Миркасыйм Госманов билгеләвенчә, татар кулъязма китабы үсешенең иң югары ноктасы мәшһүр татар дәүләтләренең яшәү дәверенә – XIV–XVI гасырларга туры килгән. Әмма Казан ханлыгы һәм аннан соң башка татар ханлыклары яулап алынгач, татарларның рухи һәм дини, гомумән, төрле яклап кысрыкланулары нәтиҗәсендә, милли китапның яшәү һәм үсү мөмкинлекләре бик тарайган. Нәтиҗәдә татар кулъязма китабының эшләнеш сыйфаты түбәнәйгән. Тик мәсьәләнең икенче ягы куәтләнгән: ата-баба динен һәм туган телне саклау юнәлешендә татар китабы төп таяныч-терәккә, көчле идеологик һәм иҗтимагый факторга әверелгән. М. Госманов билгеләвенчә, татар басма китабы китапчылык өлкәсендә бай тәҗрибә тупланган җирлектә туган. Татар кулъязма китабының сыйфатлары басма китапларга да күчкән.

Татар дәүләтләре бәйсез гомер кичергән дәверләрдә кулъязма китап күчерү эше белән махсус белгечләр, нәфис язу осталары – хаттатлар, мулла-хафизлар шөгыльләнгән. Ә ханлыклар яулап алынганнан соң, бу эшне тулаем диярлек татар шәкертләре башкарган. Шул ук вакытта аерым хаттат-каллиграфлар, муллалар һәм укымышлы затлар да китаплар күчереп язган.

XVI гасырда китап күчергән затлардан исемнәре мәгълүм ике кешене атарга мөмкин. Шуларның берсе – Адниш хафиз ибне Мөхәммәдаднаш хафиз. Ул, Мәскәүгә илче итеп җибәрелгәч, тоткынлыкка эләгә, һәм аның шул хәлендә 1554 елның җөмадиел-ахир (май) ае ур-

тасында язып төгәлләгән җыйнак кына җыентыгы билгеле. Ул хәзергәчә Мәскәүдә Россия дәүләт борынгы актлар архивында саклана. Әлеге җыентыкта «Сираҗел-колүб» һәм «Шәраигыльәхкям» исемнәрендәге ике чәчмә әсәр, шулай ук Әхмәд Ясәви һәм Сөләйман Бакыргани шигырьхикмәтләре теркәлгән. «Сираҗел-колүб» әсәренең асылы гарәп телендә булып, Адниш хафиз аны татар теленә фарсыча вариантыннан ирекле тәрҗемә иткән. Ул Казан ханлыгы чорының әдәби ядкяре булып исәпләнә.

1581 елда Хаҗи Бәйрәм бине Хаҗи Булат тарафыннан язылган гарәпчә-татарча сүзлек – XVI гасырга нисбәтле кыйммәтле кулъязма ядкярләрнең икенчесе. Ул хәзерге вакытта Казан (Идел буе) федераль университетының Фәнни китапханәсендә саклана.

Китап күчерү белән XVII–XIX гасырларда шөгыльләнгән шактый хаттатлар билгеле. Мәсәлән, китап күчергән затлардан Иванай Урсай улы, Юныс Иванай улы, Габдрахман Туймөхәммәт улы, Илми Үтәмеш улы, Сәйфелмөлек Зәйнетдин улы, Габдерәшит Мортаза улы, Җәгъфәр Ягъкуб улы, Сөбхан Габделкәрим улы, Ибраһим Ядкяр улы, Минуш Мостай улы, Сәгъдетдин Габделҗәлил улы, Мозаффар Габделгаффар улы, Габдерәхим Утыз Имәни, Габделхәмит Динмөхәммәт улы, Гобәйдулла Кәлимулла улы, Газизҗан Мөхәммәтҗан улы, Хәйрулла Габделхәбир улы, Гайса Туктаргали улы, Рәхмәтулла Әмирхани, Шиһабетдин Мәрҗани һәм тагын күп исемнәрне атарга була. Аларның күбесе гомерләре буе китап күчерү шөгыленнән аерылмаган. Татар тарихында 20 яшеннән башлап 95 яше тулганчы барлыгы 223 китап күчереп язган Габденнасыйр Сабит улы, берничә йөз данә Коръән китабы күчергән Хөсәен Әлмөхәммәт улы, 70 яше тулганнан соң да китаплар күчергән Таҗетдин Хәсән улы, 90 яшенә хәтле бу эш белән шөгыльләнгән Сәйфулла Йөртекәй улы кебек фидакяр шәхесләрнең исемнәре билгеле. Шунысын искәртергә кирәк, китап күчерү белем, тырышлык, сабырлык белән бергә бик күп вакыт та таләп иткән. Мәсәлән, Коръәнне һәм бүтән калын китапларны күчереп язу өчен 2–3 ай өзлексез тырыш хезмәт таләп ителгән.

Күркәм язулы һәм яхшылап төпләнгән кулъязма китаплар шактый кыйммәт бәягә сатылган. Мәсәлән, тарихчылар Бөгелмә өязе Әлкәй авылында күчереп язылган Коръән тәфсиренең бер томы 1841 елда 200 сумга сатылу факты һәм ул чорда бер ат бәясе 20 сум торганлыгы турында язып калдырган.

Каурый яки камыш каләм белән кулдан язылган һәм күчерелеп тиражланган кулъязма китаплар традициясе XIX гасырның икенче ярты сына кадәр дәвам иткән.

Тарихи дәверләрдәге төрле фаҗигаләр, янгыннар, шулай ук гасырлар дәвамында татар халкын милли һәм дини изү сәясәте аркасында йөзләрчә меңләгән язма китапларның аз өлеше генә безнең көннәргә хәтле килеп ирешкән.

Татар кулъязма китапларының шактый өлеше 1920–1930 елларда Совет илендә барган идеологик һәм сыйнфый көрәш дәверендә юкка чыгарылган. Кулъязма китапларның дистә меңнәрчә нөсхәдә сакланып калуы бу мирасның элек гаҗәеп зур күләмдә булганлыгын дәлилли. Хәзергәчә килеп ирешкән кулъязма татар китаплары эчтәлек ягыннан күптөрле тармакларга: дини әсәрләргә, матур әдәбиятка, халык авыз иҗатына, тарих, фәлсәфә, әдәп-әхлак, медицина, математика, география һ. б. күп фәннәргә карый.

Кулъязма китаплар эшләнеш ягыннан мөселман дөньясының китапчылык традицияләрен дәвам иткән.

Мәшһүр шагыйрь Кол Гали XIII гасыр башында иҗат иткән «Кыйссаи Йосыф» әсәре хаклы һәм лаеклы рәвештә милли әдәбиятыбызның чишмә башы дип санала. Идел-Урал буйларында яшәгән татарлар, дини сюжетка нигезләнгән «Кыйссаи Йосыф»ны күп гасырлар өзлексез укып, әсәр геройлары белән бергә кайгырганнар һәм куанганнар, юаныч һәм гыйбрәт-сабак алганнар. Бөек әсәрнең сихри һәм шигъри куәте үзеннән соңгы татар һәм, гомумән, төрки телләрдәге тугандаш халыклар әдәбиятлары үсешенә гаҗәеп зур йогынты ясаган.

Хәзерге көндә «Кыйссаи Йосыф» поэмасының фәнни оешмаларда, китапханәләрдә һәм музейларда саклана торган кулъязма күчермәләре якынча 300 берәмлек тәшкил итә.

Татар язма истәлекләренең XVIII гасырдан элеккерәк чорларда иҗат ителгәннәре иҗтимагый, тарихи һәм табигый сәбәпләр (сугышлар, көчләп чукындыру, тузу-таушалу, янып юкка чыгу, дингә каршы көрәш, башка төрле бәла-казалар) аркасында аз сакланып калган. XVI–XVII гасырларда иҗат ителгән әсәрләр урын алган кулъязмалар аеруча сирәк очрый. Әүвәлрәк язылган «Кыйссаи Йосыф» поэмасының да йөзләгән күчермәләре арасында XVII гасырга караганнары санаулы гына, барысы да диярлек XVIII һәм XIX гасырлардагы кулъязмаларда сакланган. Болар белән бергә кәгазьнең табигый саклану вакыты чикләнгән булуны да исәпкә алырга кирәк. Агач чималыннан эшләнгән кәгазьнең «гомере», яхшы шартларда саклаганда, 100 ел тирәсе булса, мамыктан ясалган кәгазьнең яше 400–500 елга җитәргә мөмкин. Шунлыктан борынгырак чорлардагы язма истәлекләрнең безнең көннәргә санаулы гына берәмлекләре килеп ирешкән.

Татар кулъязма китаплары белән фәнни кызыксыну XIX гасырның беренче дистә елларында башланган. Казан университетының татар теле укытучысы Ибраһим Хәлфин татар тарихи кулъязма чыганагының текстын өйрәнеп, аны

«Әхвали Чыңгыз хан вә Аксак Тимер» исеме астында 1822 елда Казан университеты матбагасында бастырып чыгарган. Татар шагыйре Габдерәхим Утыз Имәни гасырлар буе кулъязмалар хәлендә күпләп таралган һәм укылган борынгы әдәбиятыбыз җәүһәре «Кыйссаи Йосыф» әсәренең төрле күчермәләре нигезендә тәнкыйди текстын әзерләгән, аның беренче басмасы 1839 елда нәшер ителгән. Төрки-татар әдәби ядкярләреннән «Кисекбаш», «Ахырзаман», «Бәдәвам», «Мәликә китабы» кебек мәшһүр әсәрләр татар наширләре тарафыннан 1840–1850 елларда бастырылган, һәм шул вакыттан башлап 60–70 ел эчендә аларның дистәләгән басмалары дөнья күргән. Халык арасында кулъязмалардан укып йөртелгән бүтән иске кыйссалар һәм дастаннар, шигъри әсәрләр дә шулай ук XIX гасырда бастырып чыгарылган. Шул рәвешчә алар бөтенләй онытылу һәм югалудан саклап калынган!

Татар кулъязма истәлекләрен өйрәнгән археографларның беренчесе буларак Ибраһим Хәлфин исәпләнсә, XIX гасырда Казан университетында эшләгән галимнәрдән Христиан Френ, Карл Фукс, Александр Казимбәк, Илья Березин, Иосиф Готвальд кебекләр дә татар язма чыганакларын өйрәнүгә игътибар биргәннәр һәм бу эшкә үз өлешләрен керткәннәр. Болардан тыш XIX гасырда халкыбызның тарихи һәм әдәби язмаларын тикшерүгә татар галимнәре Габдерәхим Утыз Имәни, Хөсәен Әмирханов, Шиһабетдин Мәрҗани, Хөсәен Фәезханов һәм Каюм Насыйри күп көч куйганнар. Аларның эшен мәшһүр шәхесләр Галимҗан Баруди, Ризаэддин Фәхретдин, Габдулла Апанаевлар дәвам иткән. Татар кулъязмаларын туплап өйрәнүгә Николай Катанов та шактый өлеш керткән.

Р. Фәхретдин XX гасырның башында һәм беренче чирегендә дә татар археографик истәлекләрен туплау һәм тикшерүне дәвам иткән. Бу өлкәдә шулай ук Сабир Алимов, Сәед Вахиди, Нәүширван Яушев, Фазыл Туйкин, Гали Рәхим, Вәли Зәбиров, Габделхәй Хәбибуллин, Әбүкәрам Шакиров тырышып хезмәт куйганнар. Татарстан Мәгариф халык комиссариаты карамагында 1921–1930 елларда эшләгән Гыйльми үзәк (Академүзәк) тарафыннан кулъязма истәлекләрне барлау, туплау һәм өйрәнүгә зур игътибар бирелгән. Әмма, XX гасырның дәһшәтле 30 нчы елларында татар кулъязма ядкярләрен өйрәнүчеләрнең репрессияләнүләре сәбәпле, фәнни оешмаларда археографик эзләнүләр шактый кимегән. 1940 елларда мөгаллим һәм рәссам Сәлах Камал, танылган педагог Шәриф Сайкин, әдип, драматург һәм фольклорчы галим Нәкый Исәнбәт кебек аерым фидакяр затлар гына татар кулъязма истәлекләрен чикләнгән күләмдә барлау һәм өйрәнү белән шөгыльләнгән.

1950 еллардан алып татар кулъязма мирасын өйрәнгән галимнәрдән Гаяз Ишмөхәммәтов, Зәйнәп Максудова, Әмир Нәҗип, Габдрахман Таһирҗанов, Мостафа Ногман, Шакир Абилов, Җәвад Алмаз, Фазыл Фасиев исемнәрен атарга кирәк.

1959–1992 елларда Казан дәүләт университеты Фәнни китапханәсенең Шәрык кулъязмалары секторы мөдире булып эшләгән галим Альберт Фәтхи – татар кулъязма чыганакларын җыю һәм өйрәнү эшенә иң зур өлеш керткән белгечләрнең берсе.

1963 елда Казан дәүләт университетының фәнни-археографик экспедицияләрен оештырган һәм аларны 1987 елга хәтле җитәкләгән галим Миркасыйм Госманов татар археографиясендә тирән эз калдырды.

Филология фәннәре докторы Марсель Әхмәтҗанов 1972 елдан алып татар кулъязма чыганакларын туплауда һәм өйрәнүдә армый-талмый хезмәт куя. Ул Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты мирасханәсенең мөдире булып эшләде, меңләгән кулъязма истәлекләрне өйрәнеп, матбугатта чыгарды.

Археографик мирасны өйрәнүгә һәм пропагандалауга әдәбиятчы-текстолог галимнәрдән Хәй Хисмәтуллин, Якуб Агишев, Хатыйп Госман, Нил Юзиев, Мәсгуть Гайнетдин, Марсель Бакиров, Хатыйп Миңнегулов, Камил Дәүләтшин, Рафис Әхмәтов, Әнвәр Шәрипов, Әнвәр Хәйри, Сәлим Гыйлаҗетдинов, Нәҗип Исмәгыйлев кебекләр үз өлешләрен керттеләр. Тарихчы һәм археограф Дамир Гарифуллин татар кулъязмаларын туплаучы һәм пропагандалаучы буларак танылды. Өлкән буын галимнәргә алмашка 1980–1990 елларда Җәүдәт Миңнуллин, Фәрит Яхин, Раиф Мәрданов, Ильяс Мөстәкыймов килделәр.

XVIII гасырдан алып XXI йөз башына кадәр татар кулъязма истәлекләрен өйрәнгән археограф галимнәр, әдәбиятчы-текстологлар тырышлыгы нәтиҗәсендә дистә меңнәрчә тарихи ядкярләр сакланып калды, бик күп язма чыганаклар өйрәнелде һәм фәнни әйләнешкә кертелде. Гомумтөрки язма истәлекләр белән берраттан Идел буе татар әдәбияты һәм тарихы җәүһәрләреннән Өмми Камал, Мөхәммәтәмин, Мөхәммәдьяр, Кол Шәриф, Кадыйргали бәк, Мәүла Колый, Габди, Габдессәлам, Батырша, Габдерәхим Утыз Имәни, Колмөхәммәд Ушмави, Әбелмәних Каргалый, Габделҗәббар Кандалый, Акмулла һәм башка күп авторларның әсәрләре, «Түләк», «Чыңгызнамә», «Аксак Тимер», «Таһир белән Зөһрә» кебек мәшһүр дастаннар, «Кисекбаш», «Авык» һәм бүтән кыйссалар, тарихи елъязмалар, сәяхәтнамәләр, җыр-бәетләр кебек бай фольклор әсәрләре, шулай ук татар халкының иҗади-рухи хәзинәсенең башка мәрҗәннәре халыкка кайтарылды.

Хәзерге вакытта татар кулъязма китапларының меңләгән күчермә нөсхәләре, нигездә, Ка-

зан, Петербург, Мәскәү һәм Уфа шәһәрләрендәге архивларда, фәнни китапханәләрдә һәм музейларда саклана. Шулай ук Әстерхан һәм Төмән калалары, Урта Азия, Европа һәм Шәрык-мөселман илләренең китапханә, музей һәм архивларында саклана торган татар кулъязмалары да аз түгел.

Беренче басма китаплар

Россиядә татар телендәге иң беренче басма – Пётр I тарафыннан 1711 елда үзенең Пруссия походы уңае белән игълан ителгән Манифестның русчадан тәрҗемәсе. Гарәп хәрефләрендәге әлеге текст хәреф җыю ысулы белән түгел, ә график ысул белән башкарылган. Хәреф җыеп эшләнгән татарча беренче басма – Фарсы походы турындагы Манифест – 1722 елда Пётр I нең күчмә (йөзмә) типографиясендә дөнья күрә һәм соңрак фәндә татар милли басма китабының беренче үрнәге дип кабул ителә. Ул кинәт кенә һәм буш җирдә барлыкка килмәгән. Югарыда язылганча, язма китап культурасы бабаларыбыз арасында мең еллар элек тарала башлаган. Татар язма теле дә Урта гасырлардан алып соңгы дәвер-ләргә кадәр Көнбатыш илләре белән Шәрык халыклары арасында аралашу телләренең берсе булып хезмәт иткән. Татарча язма традицияләрнең шушы сыйфатын белгән, төрки халыклар арасында татар китабы тоткан урынның әһәмиятен яхшы аңлаган Пётр I, пропаганда максатыннан чыгып, шул мөмкинлекләрдән файдаланырга теләгән һәм беренче татар басмасы чыгуга сәбәпче булган. Манифестны татар кешесе тәрҗемә итә, аның текстын басмаханәдә татар кешесе җыя, типографиядә басучылар да татарлар була, аны татар солдатлары халык арасында тарата, димәк, ул татар укучысына да барып җитә. Нәкъ менә шуңа күрә дә әлеге Манифест татар басма сүзенең беренче үрнәге дип санала.

XVIII гасырның соңгы чирегендә берничә закон тексты татарча бастырыла, шуларның икесе – «Россия империясендәге губерналарда идарә итү тәртипләре» һәм «Җәмәгать тәртибен саклау идарәсе кагыйдәләре» – 1798 елда Исхак Хәлфин тарафыннан тәрҗемә ителгән. XVIII гасырның икенче яртысында дипломатия һәм хөкүмәт эше максатларында Шәрык телләрен өйрәнү зарурияте дәреслек китаплары әзерләп бастыру ихтыяҗын тудыра, шундыйларның берсе – Сәгыйть Хәлфиннең «Әлиф би: татар деленең әлифбиенең тәхкыйк язылган хәрефләре вә иҗекләре» («Хәреф вә иҗекләре тулы тасвирланган татар теле әлифбасы») 1778 елда Мәскәүдә нәшер ителә. 1780 елларда Петербургта Фәннәр академиясе һәм Иоһанн Карл Шнор типографияләрендә гарәп шрифтында берничә китап басыла, 1785 елда анда «Азия» типографиясе ачыла. Соңгысында 1787 елда Екатерина II әмере белән Россиядә беренче тапкыр Коръән бастырыла. (Россиядә беренче мәртәбә Коръән басылуга 225 ел тулу уңаеннан Татарстанның тарихи-мәдәни мирасы елы кысаларында республиканың Диния нәзарәте, 2012 елны Изге Коръән елы дип игълан итеп, төрле чаралар үткәрде.)

XIX гасырның беренче чирегендә татар басма китаплары күпләп дөнья күрә башлый.

Матбагалар тарихы (1800–1917 еллар)

Казанда. Китапчылык үсеше тарихы басмаханәләр барлыкка килүдән һәм алар эшчәнлегеннән аерылгысыз. Татар халкының алдынгы фикерле уллары чирек гасыр дәвамында патша хөкүмәтенә бик күп үтенечләр белән мөрәҗәгать иткәч, һәм башка халык вәкилләре бу гамәлне куәтләгәч кенә, XIX йөз башында Казанда Коръән һәм башка ислам дине китаплары бастыру өчен матбага ачарга рөхсәт бирелгән.

Казан шәһәрендә гарәп хәрефләре белән татар һәм мөселман китаплары бастыра торган беренче «Азия» типографиясе 1800 елда оештырылган. Типографияне ачу өчен 1800 елның 25 маенда император Павел I дән рөхсәт алынган һәм шул елның 13 сентябрендә ул Сенат Указы белән законлаштырылган. Типографиядә 1800 елның көзендә беренче басма текстлар чыга башлаган, ә беренче татар китаплары 1801 елда дөнья күргән. Бу матбага Казан гимназиясе карамагында булган.

«Азия» типографиясе өчен җиһазларны патша армиясендә хезмәт иткән татар кешесе, чыгышы белән Вятка губернасының Малмыж өязеннән (хәзерге Татарстанның Балтач районыннан) булган Габделгазиз Бурашев Казан гимназиясенә Петербургтан алып кайтып тапшырган. Бурашев 1796 елда ук хосусый татар типографиясе ачарга рөхсәт сорап патшага мөрәҗәгать иткән булган. Петербургта Фәннәр академиясе типографиясенең «Азия» филиалы 1785 елда Иоһанн Карл Шнор карамагына арендага алынган. Анда гарәп хәрефләре белән төрле телләрдә, шул исәптән татарча китаплар бастырылган. Казанга матбага җиһазлары белән бергә Шнор типографиясенең исеме дә ияреп кайткан һәм ул «Азия» басмаханәсе дип йөртелгән.

Габделгазиз Бурашев Казанда ачылган беренче татар типографиясен оештыруда иң зур активлык күрсәткән, ул басмаханәнең беренче арендаторы һәм нашире булган. Типографиянең 1801 елдагы беренче басмалары – «Әттәһөҗи» татар әлифбасы һәм Һәфтияк китабы. Бу типографиядә 1801–1805 еллар эчендә 7 төрле китап 17 мәртәбә бастырып чыгарылган. Болар: Әлифба, Коръән, Һәфтияк, «Сөбател-гаҗизин», «Пиргули китабы», «Устуани китабы», «Фәүзеннәҗат». Әлеге китаплар барысы да татар мәктәп-мәдрәсәләрендә дәреслек сыйфатында кулланылганнар. Шул вакыттан башлап Казанда даими

рәвештә күпләп басылып килгән Коръән, мөселман дөньясында киң таралып, Казан басмасы буларак танылган.

Беренче татар типографиясе оештырылгач, Петербургтан Казанга китап осталары Гали Рәхмәтуллин һәм Хәмзә Мамышев кайтканнар. Алар икесе дә, хәрби хезмәттә вакытларында, 1791 елда И. Шнор типографиясенә хәреф җыючы итеп җибәрелгән булганнар. Г. Рәхмәтуллин 1834 елга кадәр Казан типографияләрендә эшләгән һәм гарәп хәрефләре белән басылган китапларны җыючы оста буларак танылган. Ә Х. Мамышев 1829 елга кадәр Казандагы беренче типографиядә хезмәт күйган һәм моннан тыш, 1805–1811 елларда, татар теле укытучысы булып та эшләгән.

Казан гимназиясе идарәсе 1803 елда, Бурашев өстеннән шикаять язып, типографияне яптыру турында сүз кузгаткан һәм аны рәсми рәвештә басмаханә арендалаудан читләштергәннәр. Шулай да 1805 елга кадәр аның җитәкчелегендә китаплар чыгып килгән. Типография 1806–1809 елларда Казан сәүдәгәре Йосыф Апанаев карамагында эшләгән. Ул елларда да, нигездә, алда исемнәре күрсәтелгән китапларны бастыру дәвам иткән. Яңа басмалардан «Сәйфелмөлек» кыйссасы һәм «Мөхәммәдия» әсәре чыгарылган.

Апанаев, татар китаплары бастыру эшендә туктаусыз киртәләргә, килешү шартларының ифрат авырлыгына түзә алмыйча, 1809 елда типографияне арендалаудан баш тартырга мәҗбүр булган. Сенат Указы буенча типографияне арендалау өчен елына 500 сум гына түләү каралса да, 4 елга якын арендалап торган өчен ул 5879 сум 59 тиен акча түләгән.

Патша хөкүмәте һәм чиновниклары тарафыннан татар китабын бастыру чыгымнары бик нык арттырылган. Мәсәлән, 1809 елда рус телендәге китапларны бастыру өчен бер табакка 17 сум, гарәп хәрефләрендәге христиан миссионерлык китапларының бер табагына 25 сум, ә татар мөселман китапларының бер табагы өчен 65 сум түләү таләп ителгән. Шул сәбәпле типографияне арендага алырга теләүчеләр бүтән табылмаган, һәм аның матди ягын кайгырту гимназия өстенә калган. Китаплар бастыру шактый кимегән, 1810–1829 еллар арасында һәр елда уртача 1–4 исемдәге китап кына дөнья күргән. Кайбер елларда исә (мәсәлән, 1811, 1813, 1815 һ. б.) бер басма да чыгарылмаган.

Әбрар Кәримуллин мәгълүматлары буенча, Казандагы беренче типографиядә 1801–1829 еллар эчендә 93 басма дөнья күргән, һәм аларның гомуми тиражы 280 мең данәгә җиткән. Әлеге типография төрки халыклар арасында, төрекләрдән кала, гарәп хәрефләре белән китап баскан беренче матбага булган. Анда дини әсәрләр басылу белән бергә дөньяви китаплар да нәшер ителгән, бу киләчәктә Казанда татар китабы басу эшенең киңәюенә этәргән.

Әлеге типографиянең прогрессив эшчәнлеге үз вакытында ук күренекле галимнәр тарафыннан танылган. Академиклар Б. Дорн, Х. Френ, К. Фукс, А. Казимбәк һ. б. Казандагы беренче типографиянең эшен югары бәяләгәннәр. Профессор Николай Фёдорович Катанов: «Казан татарлары һәм Россиянең Европа өлешендә яшәүче башка вак милләтләрнең мәгарифе күтәрелү турыдан-туры Казандагы беренче «Азия» типографиясе эшчәнлегеннән башлана», – дип язган.

Казан гимназиясе каршында ачылып, казна хисабына эшләүче беренче татар басмаханәсе 1829 елда Казан университеты типографиясенә кушылган. Ә университет типографиясе исә 1809 елның 20 гыйнварында ачылган була. Бу матбаганың шул ук елда дөнья күргән беренче басмасы – университетның татар теле укытучысы Ибраһим Хәлфиннең әлифбаны һәм кыскача грамматиканы эченә алган китабы («Шаһиншаһның Казан гимназиясендә лисане төрки вә хатты гарәби үгрәтелә торган әлифба илә кечекчә нәхү вә сарыфыдыр»). Хәлфиннең икенче китабы – «Әхвали Чыңгыз хан вә Аксак Тимер» хезмәте – 1822 елда чыккан. Татар текстологиясендәге беренче әсәр буларак, бу хезмәтнең фәнни әһәмияте гаять зур.

1829 елда «Азия» типографиясе белән кушылгач, университет типографиясе Казанда татар китабы басучы бердәнбер матбага булып кала һәм Россиядә гарәп шрифтлары белән китаплар чыгара торган иң алдынгы басмаханәгә әверелә. Монда башка Шәрык халыклары телләрендә дә бик күп китаплар дөнья күргән. 1831 елда яңа хәрефләр кайтартылгач, Казан университеты типографиясендә татар наширләренең китаплары күпләп чыгарыла башлаган. Ел саен 20–40 яңа басма нәшер ителгән. Шәрыкне өйрәнүче университет галимнәренең дә гарәп хәрефләрендәге фәнни хезмәтләре күбрәк чыгарыла, татар теле грамматикасы буенча дәреслекләр дөнья күрә. 1832 елда Юнысов заказы буенча 10 мең данә тираж белән әлифба, 6600 данә Коръән һәм 3300 данә Һәфтияк нәшер ителгән. Типографиядә татар эшчеләре дә хезмәт иткән. Мәсәлән, 1844 елда 17 хезмәткәрнең 7 се татар кешесе булган.

Әлеге типографиядә 1830–1850 еллар эчендә университет һәм бүтән оешмалар өчен гарәп шрифтында 29 китап басылган. Болардан тыш татар наширләре 165 китап бастырган. Алар арасында мәктәп-мәдрәсә дәреслекләре күпчелекне тәшкил иткән. Шулай ук гарәп телендәге фикъһе китаплары, татар телендәге дини-әдәби кыйссалар, хикәятләр басылган. Мәсәлән, «Кыйссаи Йосыф» поэмасы 1839 елдан алып ел саен диярлек, кайбер елларда хәтта берничә басмада чыгарылып килгән. Татар наширләренең даими эш-

чәнлегеннән килгән файда нәтиҗәсендә типографиянең матди базасы ныгыган, эш җиһазлары яңартылган.

1815–1850 елларда, Петербург Фәннәр академиясе типографиясендә гарәп хәрефләре белән китаплар бастыру тукталган чорда, академиянең мөһим фәнни хезмәтләре Казан университеты типографиясендә басылып чыккан. Монда шулай ук Мәскәү рухани академиясе үтенече буенча да китаплар бастырылган. Казан университеты басмаханәсендә төрки-татар китапларыннан тыш гарәп һәм фарсы телләрендәге әсәрләр дә нәшер ителгән.

XIX гасырның икенче яртысында Казан университеты типографиясе Россиядәге иң куәтле һәм уникаль басмаханәләрнең берсе булып җитешкән. Анда дөньядагы бөтен телләрдәге диярлек (хәтта Азия һәм Европаның үле телләрендәге) шрифтлар, математика, химия гыйлемнәренең һәм бүтән төр тамга-билгеләр тупланган. Катлаулы шрифтлардан япон һәм кытай иероглифлары, санскрит, әрмән, монгол, уйгур хәрефләренең төрле кегльләре булган. (Кызганыч ки, бу кыйммәтле байлык Совет хакимияте урнашкач юкка чыккан.)

XIX гасырда татар наширләренең көннәнкөн үсә барган ихтыяҗларын Казан университеты матбагасы гына канәгатьләндерә алмаган. Нәтиҗәдә, зур кыенлыклар кичеп булса да, хосусый басмаханәләр ачылган. Андыйларның беренчесе 1840 елда немец эшлеклесе, гравёр Людвиг Магнус Шевиц тарафыннан оештырылган. Шевиц матбага өчен гарәп хәрефләрен Лейпцигтан алдырган. Бу типографиядә барлыгы 45 татар-мөселман китабы басылып чыккан. 1845 елда патша әмере белән Казандагы хосусый типографияләрдә татар китапларын бастыру тыелгач, Л. Шевиц та татар китапларын бастыруны киметкән. Ул, банкротлыкка чыгудан куркып, типографиясен саткан һәм туган иленә кайтып киткән. Шевицның матбагасын 1848 елда Алабуга сәүдәгәре Николай Петрович Коковин (Кукубин) сатып алган. Бу типографиядә 1841–1850 еллар эчендә татар наширләре 57 исемдәге китап бастырганнар, ә 1850–1861 елларда 153 китап нәшер ителгән.

Казан шәһәрендәге икенче хосусый басмаханә-литографияне татар кешесе Шаһи Яхин 1844 елда ачкан. Әмма 1845 елда татарча китаплар бастыру тыелгач, Яхин матбагасында татар китаплары күп чыкмаган. 1860 елларда бу басмаханә Ш. Яхинның улы Мөхәммәтвәлигә күчкән, 1870 елларда Әбдрәшитов литографиясе дип йөртелгән, 1883 елдан Касыйм Абдуллин ташбасмаханәсе буларак дәвам итеп, 1908 елда эшчәнлеген туктаткан.

Казан шәһәренең Яңа бистәсендә 1844 елда Рәхимҗан Сәгыйтов та хосусый басмаханә оештырган. Ләкин 1845 елда патша әмере белән Казанда татар китабы бастыру тыелгач, типографиянең эшчәнлеге чикләнгән. 1850 елга кадәр анда барлыгы 27 исемдәге, ә 1851–1862 елларда 53 исемдәге китап дөнья күргән.

Татар китабын хосусый матбагаларда нәшер итә башлагач, казна типографиясенең монополиясе какшаган: китап басу бәясе арзанайган, сату бәяләре дә төшкән.

1841–1850 елларда Казандагы хосусый типографияләрдә барлыгы 88 исемдәге татар китабы басылган. Шул ук вакытта университет матбагасында 119 татар китабы чыккан. Әлеге 207 исемдәге басманың гомуми тиражы 600 меңнән артып киткән. Ул чорда татар наширләре буларак Казан сәүдәгәрләре Апанаевлар, Юнысовлар, Сәетбоһановлар, Сәгыйтовлар, Хәсән Карташев, Миңнебай Әхмәтов, Гобәйдулла Габдесаттаров; мещаннардан Мортаза Максутов, Исхак Уразов һ. б. затлар тырышлык куйганнар. Шәкерт-студентлар, крестьяннар, хәтта хатын-кызларның да наширлек белән шөгыльләнү очраклары күзәтелгән. Китап чыгаруга бу кадәрле төрле катлау вәкилләренең тартылуы халыкның белемгә омтылышы зур булу белән аңлатыла.

Хосусый татар матбагалары патша хөкүмәтенең эзәрлекләүләре һәм тыюлары аркасында ябылырга мәҗбүр булганнар. Татарларның хосусый матбагалары яңадан XIX гасыр ахырында гына ачылган.

Казандагы басмаханәләрдә 1801–1855 еллар арасында 577 татар китабы басылган. Ул чорда, Мәскәү һәм Петербургтан тыш, Россиянең барлык провинциаль типографияләрендә барлыгы 1463 китап нәшер ителгән. Димәк, бу басмаларның өчтән бер өлешен татар китаплары тәшкил иткән. Шунысын да искәртергә кирәк, XIX гасырның беренче яртысында, Россиядәге бүтән төрки халыкларның берсендә дә китап басылмаганлыктан, татар китаплары башка төркиләр арасында да күп таралган.

XIX гасырның беренче яртысында Казан шәһәрендә барлыгы 401 татар китабы дөнья күргән. 1840 еллар уртасында татар китабы бастыру тыелгач, китаплар бөтенләй чыкмаган диярлек. Ә тыю бетерелгәч, 1850 елларда, һәр ел саен 30–50 исемдәге китап басылган. 1860 елларда исә, христиан миссионерларының эзәрлекләве нәтиҗәсендә, ел саен нибары 15–20 китап кына чыккан. Татар китапларын бастыру бары тик 1890 еллар башында гына арта. Ул вакытта бер елда 100 дән артык исемдәге, тиражы белән 1 миллионга якын китап нәшер ителгән.

Басмалар саны буенча ул чорда Россия империясендә беренче урынны рус, икенче урынны латыш һәм өченче урынны татар китаплары биләгән. Гомуми тираж ягыннан караганда, татар китаплары рус китапларыннан кала икенче урында торган.

Казан типографияләрендә чыккан татар китапларының саны артуга карамастан, халыкның китапка ихтыяҗы канәгатьләндерелмәгән. XIX гасыр дәвамында элеккеге гадәт буенча кулъязма китаплар күчереп язу һәм тарату дәвам иткән. Шулай ук Шәрык илләреннән ел саен меңләгән китап кайтарылып торган.

XIX гасыр ахырында Казандагы 14 рус типографиясенең һәммәсендә дә татар китаплары басылган.

Перов матбагасы. 1879–1900 еллар арасында Иван Семёнович Перов типо-литографиясендә 36 татар китабы 518 500 данә тираж белән дөнья күргән. Ә 1901–1910 елларда анда 31 китап 373 080 данәдә басылган.

Вечеслав матбагасы. Казандагы рус матбугаты цензоры Георгий Михайлович Вечеслав 1881 елда типография ачкан. 1882 елда ул, гарәп хәрефләрен дә койдыртып, татар китаплары бастыра башлаган. Бу матбагада 1882–1894 елларда 225 исемдәге татар китабы 1,5 миллион тирәсе гомуми тираж белән басылып чыккан. Вечеслав басмаханәсендә дөньяви китаплар, аеруча фольклор әсәрләре, матур әдәбият, тарихи эчтәлектәге әсәрләр нәшер ителгән. Бу типографиядә, И. Н. Харитонов эшли башлагач, китаплар полиграфик яктан югары сыйфатлы итеп (яхшы кәгазьдә, матур шрифтлар белән, бизәк-нәкышләр кулланып) басылган.

Чиркова матбагасы. Мария Арефьевна Чиркова варислары типографиясе үзенең башлангычын 1840 елда ачылган Л. Шевиц матбагасыннан һәм аннары Алабуга сәүдәгәре Н. Коковинныкы буларак танылган басмаханәдән алган. XIX гасырда татар китаплары нәшер итү буенча бу басмаханә университет типографиясеннән генә калышкан. 1870–1880 елларда анда татар китаплары гына басылган диярлек. Ә XIX гасыр ахырында, башка типографияләрнең дә ачылуы һәм үзендә матбагачылык эшен камилләштерәү сәбәпле, Чиркова басмаханәсендә татар китапларын бастыру кимегән. Шул сәбәпле 1906 елда бу типографиядә татар китапларын бастыру тукталган.

Әлеге басмаханәдә 1901–1905 еллар эчендә 171 исемдәге татар китабы 2 миллион 481 990 данә тираж белән басылган.

Домбровский матбагасы. Казан шәһәрендәге теш табибы Бронислав Людвигович Домбровский типографиясендә татар китаплары аеруча күп басылган. Ә. Кәримуллин ачыклавынча, Вечеслав типографиясен Домбровский сатып алган. 1894 елда ачылуыннан алып 1910 елга хәтле анда барлыгы 622 татар китабы 4 миллион 616 050 данә тираж белән басылган. Монда дини китаплар һәм кадими мәдрәсәләр өчен дәреслекләр күп чыккан.

Бу матбагада 1894–1900 елларда татар китаплары уңышлы гына чыгып килсә дә, 1901–1907 елларда басмалар саны чагыштырмача аз булган. Сәбәбе – матбагачылык эшендәге үсеш һәм үзгәрешләрне исәпкә алмыйча, китапларны элеккечә кыйммәт бәягә, иске шрифтлар белән начар сыйфатлы кәгазьдә бастыру. Бу типография 1917 елга кадәр эшләгән.

Антонов матбагасы. 1894 елның декабрендә ачылган Леонид Петрович Антонов типо-литографиясендә санаулы гына татар китаплары чыгып килгән. Ә 1911–1913 елларда анда татар китаплары 76 исемдә, 295 мең данә гомуми тираж белән нәшер ителгән. Антонов матбагасының ул елларда эшчәнлеге «Мәгариф» нәшрияты белән тыгыз бәйле булган.

Кәримевләр матбагасы. Бертуган Мөхәммәтҗан һәм Шәрифҗан Кәримевләр мәшһүр татар тарихчысы һәм дин эшлеклесе Шиһабетдин Мәрҗанинең шәкертләре булганнар. Алар Ш. Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» хезмәтенең беренче томын ике тапкыр (1885 һәм 1897 елларда) нәшер иткән.

Кәримевләр 1890 еллар башында Казанда, Мәкәрҗә, Минзәлә һәм Сембер ярминкәләрендә китап сәүдәсе эшен җәелдереп җибәргәннәр. 1898 елда алар китап сәүдәсе фирмасын оештырганнар, 1899 елның гыйнварында типография ачарга рөхсәт алганнар.

1900 елның 1 мартында эшли башлаган бертуган Кәримевләр матбагасы шул елда барлыгы 36 исемдәге китапны 433 100 данә тираж белән нәшер иткән. Ә 1901 елда әлеге басмаханә, 97 исемдә (гомуми тиражы 195 510 данә) китап нәшер итеп, татар китабы бастыру буенча беренче урынга чыккан. Бу типография Казанда 1905 елга кадәр бердәнбер татар матбагасы булган.

1901–1917 еллар арасында Кәримевләр матбагасында барлыгы 1700 исемдәге китап басылган, һәм аларның гомуми тиражы 20 миллион данәгә якын булган. Бу – шул ук чорда Казанда басылган татар китапларының өчтән бер өлешенә туры килә. Китапларның күпчелеген алар үз хисапларына нәшер иткәннәр.

Бертуган Кәримевләр үз типографияләре белән берлектә хәреф коюны оештырулары, үтемле дини китаплар, халык яратып укыган кыйссалар һәм фольклор әсәрләрен бастырып, китап сәүдәсе белән актив шөгыльләнүләре нәтиҗәсендә, китапчылык эшендә югары уңышларга ирешкәннәр. Шулай ук аларның арзанлы һәм түбәнрәк сыйфатлы кәгазьдә вак шрифт белән бастырып, китапның сәнгати эшләнешенә зур таләпләр куймаулары да басмаларның арзан бәягә сатылып, күбрәк таралышына ярдәм иткән.

Кәримевләр матбагасында чыккан китаплар эчтәлек ягыннан бөтен төр китапларны да, ягъни матур әдәбият, дини китаплар, фольклор әсәрләре, дәреслекләр, фәнни-популяр хезмәтләр, тәрҗемә әсәрләр, балалар әдәбияты һ. б. үз эченә алган.

Харитонов матбагасы. Казандагы Иван Николаевич Харитонов басмаханәсе татар китаплары бастыру белән шөгыльләнгән рус типографияләре арасында күренекле урын алып тора. Иван Харитонов 10 яшеннән Казан университеты типографиясендә хәреф җыючы булып эшли башлаган. Ул анда рус һәм Европа телләрендәге, шулай ук татар, монгол һәм еврей телләрендәге текстларны җыярга өйрәнгән. Типография эшендә зур осталыкка ирешкән Харитонов, Казандагы башка басмаханәләрдә дә эшләп, бай тәҗрибә туплаган. 1888 елда ул Г. М. Вечеслав типографиясенә идарәче булып урнашкан. Бу типография И. Н. Харитонов тырышлыгы белән тиз арада алдынгы сафка чыккан.

Харитонов Мәскәү һәм Петербургтагы типографияләр эше белән танышып кайткан һәм 1896 елда үз типографиясен ачып җибәргән. Харитонов типографиясе тиз арада уңышлар яулаган. Башта анда 5–6 гына кеше эшләсә, 3 елдан эшчеләр саны 40–50 гә, ә 1909 елда 130 кешегә җиткән.

1902 елда И. Харитонов, Көнбатыш Европа илләренә барып, матбагачылык һәм полиграфия тәҗрибәсен өйрәнгән. Үз басмаханәсен чит ил типографияләре үрнәгендә камилләштергән. Шул ук 1902 елдан алып Харитонов матбагасында да татар китаплары басыла башлаган. Бу типография берничә елдан татар китапларын иң күп бастыра торган матбагаларның берсенә әверелгән. Анда 1902–1916 еллар эчендә 700 исемгә якын татар китабы 3 миллион 300 меңнән артык данәдә басылып чыккан. Эчтәлек ягыннан караганда, аларның күбесен матур әдәбият әсәрләре тәшкил иткән. Иң күбе татар әдипләренең (Г. Тукай, Ф. Әмирхан, М. Гафури, Р. Фәхретдин, Ф. Халиди, Г. Ильяси, Г. Рәхим, С. Җәлал, Н. Думави, З. Бәшири, К. Бәкер һ. б.) китаплары булган. А. С. Пушкин, Л. Н. Толстой, Н. В. Гоголь, И. С. Тургенев кебек авторлар әсәрләреннән тәрҗемәләр дә байтак басылган. Шулай ук татар һәм рус фольклоры әсәрләре, төрле фәннәр буенча уку китаплары, дәреслекләр, сүзлекләр дөнья күргән.

1916 елда Харитонов типографиясе бертуган Әхмәдуллиннарның «Өмид» матбагасы белән берләшкән һәм «Сабах» фирмасы карамагында эшләвен дәвам иткән.

XX гасыр башында Казандагы 20 типографиядә барлыгы 5154 исемдәге татар китабы басылган һәм аларның гомуми тиражы 39 миллионга якын булган. Бу чорда басылган барлык татар китапларының 75–85 проценты Казанда чыккан. Әлеге Казандагы басмаханәләр арасында беренчелекне бертуган Кәримевләр типографиясе тоткан.

Вараксин варислары матбагасы. Казан шәһәренең почётлы гражданы Владимир Васильевич Вараксин типо-хромо-литографиясендә 1904–1916 елларда 27 татар китабы 118 470 данә гомуми тираж белән басылып чыккан.

Ермолаева матбагасы. Казан шәһәрендәге татар китапларын бастыруга зур өлеш керткән типографияләрнең берсе Инна Вениаминовна Ермолаева матбагасы булган. Бу типо-литография сәүдәгәр В. М. Ключников тарафыннан 1881 елда ачылган. 1906 елның март аенда Ключников үз типографиясен кызына – И. В. Ермолаевага тапшырган. Ермолаеваның ире дә Казандагы А. М. Петров типографиясен сатып алып, ике матбаганы берләштергәннәр. Беренче елда анда 13 исемдәге татар китабы чыккан, шуларның 9 ы цензура эзәрлекләвенә дучар булган. Бу типографиядә революцион һәм демократик рухтагы басмалар күп чыгуны гаеп итеп, 1906 елның ахырында аның хуҗалары Ермолаевлар җавапка тартылган һәм Казаннан сөрелгән. Тик 1907 елның язында кире кайтканнар. Ләкин губерна идарәсе, бу матбагага карата дошманлыгын саклап, 1909 елның апрелендә типографияне яптырган.

Ермолаева типографиясендә барлыгы 70 исемдәге татар китабы чыккан, шуларның 40 ы «Мәгариф» нәшрияты тарафыннан нәшер ителгән. Китапларның күпчелеге дәреслекләр, уку китаплары, русчадан тәрҗемә әсәрләр, сүзлекләр һәм фәнни-популяр китаплар булган.

Губернатор тарафыннан даими эзәрлекләнү нәтиҗәсендә 1909 елда ябылган И. В. Ермолаева типографиясен дворянка Надежда Мариусовна Чижова сатып алган. Галим Ә. Кәримуллин язуынча, типография хуҗасының алышынуы шартлы гына булып, наширләр һәм барлык заказчылар элеккечә үк калган. 1909–1910 елларда бу типографиядә 37 исемдәге китап 140 500 данә гомуми тираж белән басылып чыккан.

1910 елда Чижова матбагасын В. З. Еремеев сатып алган. 1911 елда бу типография В. Еремеев һәм А. Шашабрин Сәүдә йорты грифы белән танылган. Бу исем астындагы типографиядә 1910–1915 елларда 62 исемдәге татар китабы 377 140 данә гомуми тираж белән нәшер ителгән. Беренче Бөтендөнья сугышы башлану белән бәйле рәвештә кәгазь кыйммәтләнгәч, анда китаплар бастыру кимегән.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Ермолаева – Чижова – Еремеев һәм Шашабрин Сәүдә йорты матбагасында барлыгы 169 татар китабы 710 340 данә тираж белән басылып чыккан.

Шәрәф матбагасы. 1905 елда Россиядәге сәяси һәм иҗтимагый үзгәрешләр тәэсирендә барлык милләтләргә матбугат иреге бирелгән. Ягъни татарлар да газета-журналлар чыгару, типографияләр ачу, наширлек һәм китап тарату ширкәтләре төзү, китапханәләр оештыру хокукына ия булган. Ләкин чынлыкта матбугат иреген тормышка ашыру җиңел бармаган. Хакимият цензура, жандармнар, чиновниклар башбаштаклыгы кебек төрле киртәләр корган.

Шактый тоткарлыклардан соң, 1906 елның 13 ноябрендә, бертуган Гыйльметдин һәм Борһан Шәрәфләр үз матбагаларын ачалар. Шәрәф матбагасы Владимир Емельянович Казаков йортындагы «Болгар» номерларында урнаша. Г. Шәрәф 1903–1904 елларда Петербургта Шәрык типографияләренең иң күренеклеләреннән булган Ильяс Бораганский басмаханәсендә матбагачылык эшенә өйрәнгән.

1906 елның ике аенда бу типографиядә 13 исемдәге китап чыккан. 1907 елда 52 һәм 1908 елның беренче яртысында 41 исемдәге китап дөнья күргән. Анда күбесенчә әдәби, фәнни-популяр эчтәлектәге китаплар басылган, шулай ук революцион әсәрләр дә нәшер ителгән.

Бу типографиянең даими наширләре Казандагы «Мәгариф» һәм «Сабах», Троицкидагы «Хезмәт» кебек нәшрият һәм китапханәләр булган.

1908 елның 30 июнендә Шәрәф матбагасы Казан губерна идарәсе тарафыннан ябылган. Шул елның ноябрь аенда аны Галимирза Саинов сатып алган. Типография башта яңа хуҗаның исеме белән Саинов матбагасы дип йөртелә, аннан соң «Үрнәк» дип атала башлый. 1908 елның ноябреннән 1911 елның гыйнварына кадәр «Үрнәк» типографиясендә гомуми тиражы 480 665 нөсхәдән торган 152 исемдәге китап бастырылган. Шуларның 79 исемдәгесе – матур әдәбият, 12 се – дини китаплар, калганнары – дәреслекләр, фәнни-популяр китаплар, календарьлар һәм бүтән басмалар. Заманының алдынгы фикерле яшь әдипләре Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал, М. Гафури, Н. Думави китаплары, рус әдипләреннән А. С. Пушкин, Л. Н. Толстой, М. Горький, Н. В. Гоголь һ. б. әсәрләренең татарчага тәрҗемәләре басылып чыккан. «Үрнәк» типографиясендә басылган китапларның яртысына якыны типографиянең үз хисабына нәшер ителгән.

Матбаганың эшчәнлеге дәүләт өчен зарарлы дип бәяләнеп, патша хөкүмәте тарафыннан 1911 елның февралендә ябылган. Типография урнашкан йортның хуҗасы В. Е. Казаков 1911 елның язында «Үрнәк» матбагасын үзенә сатып алган. Ләкин, Г. Саинов чорындагы кебек үк, бу юлы да басмаханәнең чынбарлыктагы хуҗасы Г. Шәрәф булып калганлыгы ачыкланган, шул елның 26 июнендә типография тагын ябылган. Казаков карамагында дип исәпләнгән 1–1,5 ай эчендә бу матбагада 14 исемдәге (гомуми тиражы 49 500 данә) китап басылган.

1913 елда «Мәгариф» китапханәсе җитәкчеләреннән Мөхәммәтәмин Мостафин ачкан «Мәгариф» типографиясе Казаков басмаханәсенең турыдан-туры дәвамы булган. «Мәгариф» типографиясендә 1913–1917 елларда барлыгы 147 исемдәге татар китабы басылган, аларның гомуми тиражы 530 350 данәгә җиткән.

«Бәянелхак» матбагасы. Казан сәүдәгәрләре Әхмәтҗан һәм Мөхәммәтҗан Сәйдәшевләр, үзләре нәшер иткән «Бәянелхак» газетасын (1906–1914) бастыру өчен, 1907 елда махсус типография ачканнар. Анда 1907–1912 елларда басылган 75 исемдәге китапның гомуми тиражы 220 100 данә тәшкил иткән.

«Бәянелхак» матбагасында дини һәм әдәби китаплар, фәнни-популяр әсәрләр басылган. Бертуган Сәйдәшевләр басмаханәләре өчен шрифтларны Мәскәүдәге Отто Гербек типографиясеннән алдырганнар.

«Милләт» матбагасы. 1908 елның сентябрендә «Идрисов, Галиев вә шөрәкясе»нең типографиясе ачылган. Шул вакыттан алып бу ширкәт «Милләт» исеме белән эш йөрткән.

Бу матбагада 1908–1916 елларда барлыгы 256 исемдәге татар китабы 1 миллион 376 015 данә гомуми тираж белән басылып чыккан. «Милләт» матбагасында күпчелеге мәктәп һәм мәдрәсә дәреслекләре, балалар өчен күптөрле уку китаплары, дини китаплар, шулай ук фәнни хезмәтләр дөнья күргән.

Ибраһим Идрисов, типография ачылганчы, үз улы Мөхәммәтне Петербург, Мәскәү һәм Истанбулга матбагачылык эшен өйрәнергә җибәргән. «Милләт» типографиясе ачылгач, анда матур шрифтлар хәзерләнгән. «Милләт»нең шрифтлары һәм китап бастыру сыйфаты югары дәрәҗәдә булган. Барлык шрифт төрләренең үрнәкләрен татар китап сәнгатенең танылган остасы гравёр Мөхәммәт Идриси әзерләгән. Ул шулай ук төсле географик карталар сызган һәм рәсемнәр ясаган. «Милләт»тәге кебек хәрефләр күптөрлелеге бер типографиядә дә булмаган. Анда коелган гарәп шрифтлары Казан, Уфа, Әстерхан һәм Урта Азия басмаханәләренә дә сатып алынган.

«Өмид» матбагасы. Китап сәүдәсе һәм нәшрият эшчәнлеге белән XIX гасыр ахырыннан шөгыльләнеп килгән бертуган Габделвәли һәм Мөхәммәтгали Әхмәдуллиннар 1908 елда «Сабах» ширкәтен оештырганнар. Алар 1911 елның җәендә үзләренең «Өмид» типографиясен дә ачканнар. Бу матбага тиз арада үсеш алган, анда хәреф кою, литография һәм цинкография дә булдырылган. «Өмид»тә басылган китаплар сыйфат ягыннан югары дәрәҗәгә ия булган. 1911–1917 елларда бу басмаханәдә 401 исемдәге татар китабы 1 миллион 347 575 данә тираж белән басылып чыккан. Аларның шактый өлеше фәнни-популяр басмалар булган. Шулай ук әдәби һәм тарихи әсәрләр дә дөнья күргән.

Петербургта. XVIII гасыр ахырында Петербургта Иоһанн Карл Шнорның «Азия» типографиясе эшләве һәм анда татар китаплары да бастырылуы турында әйткән идек. Императрица Екатерина II, татарларның үтенечләрен исәпкә алып, махсус фәрман белән хөкүмәт хисабына Шнор

типографиясендә 1787 елда Россиядә беренче мәртәбә Коръән китабын бастырткан. Аннан соңгы 1790, 1793, 1796 һәм 1798 елларда Коръәнне тагын бастырганнар.

Бакчасарай шәһәрендә дөньяга килгән Кырым татары Ильяс мирза Бораганский 1894 елда Петербург шәһәрендә хосусый типографиясен ачкан. Бу типография 1840 елларда Казанда ачылган хосусый матбагалардан кала Россиядәге беренче хосусый татар басмаханәсе булган.

Бораганский, Кырымда белем алгач, Төркиядә укыган. Шул чорда ул гарәп каллиграфиясен өйрәнеп, гравёрлык һәм рәссамлык серләрен үзләштергән. 1882 елда Петербургка барган. Анда Бораганскийның Шәрык әдәбиятын һәм күп телләр белүенә игътибар итеп, Петербург университетына каллиграфия укытучысы һәм төрек теле лекторы итеп эшкә чакырганнар. Шәрыкне өйрәнүче галимнәрнең киңәше белән ул «И. Бораганский һәм ширкәте» типографиясен ачып җибәргән. Бораганскийның компаньоны Петербург ахуны Гатаулла Баязитов булган.

Петербургта гарәп хәрефләре белән китап бастыра торган матбага ачылу үз чорында башкала тормышында зур яңалык буларак бәяләнгән. Ул Шәрыкне өйрәнүче галимнәрнең хезмәтләрен бастыру өчен кулай булуы белән бергә татар һәм мөселманнарның мәдәни яшәешенә дә зур өлеш керткән.

Баязитов тарафыннан 1905–1914 елларда нәшер ителгән беренче татар газетасы «Нур» шул типографиядә басылган, һәм әлеге матбага да «Нур» типографиясе дип аталган.

Бу матбагада 1894–1900 еллар эчендә гарәп хәрефләре белән 270 мең данәдә 60 китап басылып чыккан. 1901–1910 еллар арасында Бораганский («Нур») матбагасында 68 исемдәге татар китабы 148 440 данә тираж белән басылган.

Югары полиграфия сыйфаты өчен бу типография медаль белән бүләкләнгән.

Бөтен Россиядә мөселман матбугаты көчле эзәрлекләнгән чорда Бораганский типографиясендә 1911–1917 елларда Шәрык телләрендәге китаплар чыкмаган.

Татар җәмәгать һәм дин эшлеклесе Габдерәшит Ибраһимов тарафыннан Петербургта 1906 елда икенче татар типографиясе оештырылган. Ул, нигездә, «Өлфәт» газетасын һәм бүтән вакытлы матбугат органнарын бастыру өчен ачылган булса да, анда китаплар да нәшер ителгән. Бу матбагада 1906–1907 елларда 25 исемдәге татар китабы 66 900 данә тираж белән дөнья күргән. «Өлфәт» типографиясе, эшли башлагач та, цензура һәм полиция тарафыннан эзәрлекләнгән, аңа штрафлар салынган, ябылган һәм яңадан ачылган...

1914 елда Петербург каласында Мөхәммәтгалим Максудовның татар типографиясе ачылган. 1914–1916 елларда анда 24 исемдәге татар китабы 84 113 данәдә басылган. Бу типографиядә чыккан китапларның шактые Беренче бөтендөнья сугышы белән бәйле законнар турындагы басмалар булган.

Оренбургта. XX гасыр башында Оренбург шәһәре татар милли-мәдәни үзәкләренең берсе булган.

Оренбургта яшәгән Берк Бреслин дигән кеше, 1880 елларда үз типографиясендә гарәп шрифты булдырып, татар китаплары бастыра башлаган. Ләкин анда чыккан китаплар санаулы гына булган.

1900 елда Гыйльман ахун Кәримев, Оренбургтагы бер рус кешесеннән типография, Бреслиннан исә гарәп шрифтларын сатып алып, үз матбагасын оештырган. Анда 1901 елдан алып 1902 елның уртасына кадәр 27 исемдәге татар китабы басылган, гомуми тиражы 52 400 данәне тәшкил иткән. 1902 елда Гыйльман ахун вафат булгач, типография аның улы Фатих Кәрими карамагына калган. Ул, Төркиядә белем алганда һәм аннан соң Кырымда, 1898 елда Шакир Рәмиев белән Европа илләрендә (Германия, Франция, Бельгия, Италия һ. б.) сәяхәт кылганда, аннары Мәскәү белән Петербургта, типография эшенең серләрен өйрәнеп кайткан була.

Кәримев матбагасы яхшы гына эшләп китә. 1905 елның ахырында Ф. Кәрими тәкъдиме белән «Кәримев, Хөсәенов вә шөрәкясе» исемендәге нәшрият оештырыла. 1906 ел ахырында социал-демократик һәм большевистик брошюралар бастырылып, типографиянең ябылу куркынычы тугач, 1907 елда Ф. Кәрими үз матбагасын шушы нәшрият исеменә күчергән. Типографиядә 1907 елда да русчадан тәрҗемә ителгән социал-демократик китапчыклар басылганнан соң, патша цензурасы шикаяте нигезендә аңа арест салына, һәм ул 1908–1909 елларда эшләми. 1910 елда биредә берничә китап кына басылган.

«Кәримев, Хөсәенов вә шөрәкясе» Оренбургтагы рус типографиясен дә сатып алып үзенә кушкан. Яңа техник җиһазлар һәм шрифтлар алганнан соң, бу типография Оренбургтагы иң куәтле басмаханәгә әверелгән. Анда китаплардан тыш татар һәм рус вакытлы матбугаты да нәшер ителгән. Әлеге нәшрият Уфа шәһәрендә дә бүлекчәсен һәм матбагасын («Шәрык» матбагасы) ачып җибәргән.

1901–1917 еллар арасында «Кәримев, Хөсәенов вә шөрәкясе» типографиясендә 384 татар китабы басылып, аларның гомуми тиражы миллионга якын булган. Фатих Кәриминең күпсанлы үз әсәрләре һәм дәреслекләре, шулай ук тәрҗемәләре бу типографиядә чыккан. Ризаэддин Фәхретдиннең дини, әдәби һәм тарихи хезмәтләре дә әлеге матбагада дөнья күргән. Башка татар авторларының дәреслекләре, педагогик, тарихи һәм фәлсәфи хезмәтләре, әдәби әсәрләре, фәнни-популяр китаплар нәшер ителгән.

1906 елда Оренбургта иске карашлы татар дин әһелләре үзләренең матбугат органы «Дин вә мәгыйшәт» журналын чыгара башлаганнар, һәм шуны бастыру өчен типография оештырылган. Журнал исеме белән үк аталган басмаханәдә китаплар да нәшер ителгән. Анда күбесенчә кадимчелек тарафдарларының китаплары чыккан. Бу типографиядә барлыгы 104 исемдәге китап 175 750 данә тираж белән басылган.

Оренбургта яшәгән Закир һәм Шакир Рәмиевләр, 1906 елда «Вакыт» газетасы һәм 1908 елда «Шура» журналы нәшер итү максаты белән, үз типографияләрен оештырганнар. Рәмиевләрнең 1909 елда эшли башлаган «Вакыт» матбагасында, газета һәм журналдан тыш, китаплар да бастырылган. Анда 1909–1917 елларда барлыгы 116 исемдәге татар китабы 322 450 данә гомуми тираж белән нәшер ителгән. Галим Әбрар Кәримуллин мәгълүматларына караганда, «Вакыт» типографиясенең җитәкчесе шул ук исемдәге газетаның мөхәррире Фатих Кәрими булган.

Оренбургта чыккан татар китаплары, Казан басмаларына караганда арзанрак булу сәбәпле, тиз арада таралып беткән. Әлеге матбагада шулай ук казах телендәге китаплар да басылган.

Уфада. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында Уфада эшләүче рус типографияләрендә берничә исемдә генә татар китабы дөнья күргән.

1905 елдан алып Уфа губерна идарәсе типографиясендә гарәп шрифтлары белән татар китаплары бастыру эше җанланган. Бу басмаханә 1908 елга хәтле Уфада татар китаплары чыгарып килгән бердәнбер матбага булган. Анда барлыгы 15 исемдәге татар китабы нәшер ителгән.

Уфада беренче хосусый типография 1908 елда «Шәрык» матбагасы исемендә, Оренбургтагы «Кәримев, Хөсәенов вә шөрәкясе»нең филиалы буларак ачылган. Бу типография 1914 елда Казан китапчылары – бертуган Кәримевләргә сатылган, ә исеме сакланып калган. Ләкин миссионерлар шикаятьләре аркасында типография эшенә зур зарар салынган, китап бастыру шактый кимегән.

1908–1917 елларда бу матбагада 600 мең данәдән артык тираж белән 200 исемдәге татар китабы чыккан. Шулардан дини эчтәлектәге китаплар аз булып, басмаларның күпчелеген матур әдәбият һәм халык авыз иҗаты әсәрләре, дәреслекләр һәм фәнни-популяр китаплар тәшкил иткән.

Уфа каласында 1914 елда «Тормыш» типографиясе оештырылган. Анда 1917 елга кадәр 42 400 данә тираж белән нибарысы 11 татар китабы чыккан.

Троицкида. XX гасыр башында Троицк шәһәрендә «Хезмәт» китап нәшрияты оештырылган. Әлеге нәшрият тырышлыгы белән 1905 ел ахыры – 1906 ел башында Троицкидагы рус типографиясендә дистәләп татар китабы басылган.

Уральскидагы Камил Мотыйгый матбагасында һәм ***Семипалатттагы*** «Ярдәм» ширкәте тарафыннан дистәләп исемдәге татар китаплары басылып чыккан.

Мәскәүдә. XVIII гасырның соңгы чирегендә Мәскәү университетында гарәп шрифтында чыккан китаплардан соң, бу шәһәрдә XIX гасырда санаулы гына татар басмалары дөнья күргән. XX гасыр башында да Отто Гербек типографиясендә, Шәрык телләре институтында (Лазарев институты), 1910–1915 елларда Михаил Осипович Аттай матбагасында берничә генә татар китабы чыккан. Боларда һәм Мәскәүнең тагын берничә типографиясендә XX гасыр башында нибарысы 14 татар китабы 28 мең данә гомуми тираж белән басылган.

Әстерханда. Әстерхан шәһәрендә Шиһабетдин Мәрҗанинең шәкерте Габдрахман Гомәри матбага ачып, XX гасыр башында татар китаплары бастыра башлаган. 1908–1914 елларда «Г. Гомәри вә шөрәкясе» типографиясендә 58 татар китабы 123 425 данә гомуми тираж белән дөнья күргән. Әлеге китапларның бөтенесе диярлек Г. Гомәри тарафыннан нәшер ителгән.

Әстерханда цензура аеруча рәхимсез булганлыктан, андагы татар матбугаты эзәрлекләнгән, газета һәм журналлар яптырылган. Цензураның тагын да көчәюе нәтиҗәсендә, Әстерханда 1914 елда татар китапларын бастыру бөтенләй тукталган. Андагы татар матбугаты һәм мәдәнияте әһелләре башка шәһәрләргә күчеп китәргә мәҗбүр булганнар.

1917 елның Февраль революциясеннән соң Әстерханда татар матбугатын бастыру яңарган, анда «Нәшрият» типографиясе ачылган.

Эстәрлетамакта. 1910 елда Эстәрлетамак шәһәрендә «Нур» татар типографиясе ачылган һәм 1914 елга кадәр (хөкүмәт тарафыннан ябылганчы) анда 30 татар китабы басылган. Чыккан китапларның гомуми тиражы 52 мең данә тәшкил иткән.

Әбрар Кәримуллин мәгълүматларына караганда, XX гасыр башында ел саен 500 дән артыграк китап чыгып килгән. 1901–1917 елларда барлыгы 7 меңгә якын исемдәге татар китабы басылган, һәм аларның гомуми тиражы 47 миллионнан артып киткән. 1917 елга кадәр барлыгы 15 мең исемдәге татар китабы басылган. Ул чор татар китапларының гомуми тиражлары Россия халыклары арасында руслардан кала икенче урында торган. Татар авторларының китаплары белән берәттән Көнчыгышның бөек әдипләре һәм философлары Газали, Мәгарри, Фараби, Низами, Фирдәүси, Рудаки, Хәйям, Дәһләви, Европаның бөек классиклары Ж.-Ж. Руссо, Һ. Һейне, Ф. Шиллер, Дж. Байрон, Г. Сенкевич, Һ.-К. Андерсен, Ж. Верн һ. б. язучыларның әсәрләре дә туган телебездә басылып чыккан.

Башка төрки телләрдә китап чыгару

Казанда татар китаплары бастыру башлангач та, татар наширләре гарәп һәм фарсы телләрендәге китапларны да чыгарганнар. Тирәбара төрек, азәрбайҗан, казах, үзбәк һ. б. төрки телләрдәге китаплар да нәшер ителгән.

Төрки телләрдәге күп кенә беренче китаплар татар матбагачылыгы нигезендә дөнья күргән. Шуның белән берлектә татар телендәге китаплар Идел буе, Кавказ, Урта Азия халыклары арасында таралган. Татар наширләре бастырган китаплар Төркия, Көнчыгыш Төркестан, Һиндстан, Иран һәм гарәп илләренә дә, Европа һәм Америкадагы Шәрыкне өйрәнүче галимнәргә дә барып ирешкән.

Татарларның казах телендә китаплар бастырып, әлеге милләт халкы арасында таратуга зур әһәмият бирүләренең төп сәбәбе изге ният белән бәйле. XVIII гасыр ахырларыннан алып XX гасыр башына кадәр татарлар казах кардәшләрдә мөселман динен ныгыту һәм аларның белемле булуы өчен күп тырышлык куйганнар. Иң *башлап башкортлар, казахлар яшәгән җирләрдә мәктәп-мәдрәсәләр оештырып, белем-мәгърифәт таратучылар татарлар булган.* XX гасыр башында үзбәк, төрекмән, кыргыз һәм таҗикларны мәгърифәтле итүгә дә татарлар күп көч куйганнар.

Казах телендәге беренче китап 1831 елда Казан университеты типографиясендә басылган.

1840 еллардан Казанда төрки халыкларның әдәбият үрнәкләрен бастыру башланган. XIX гасырның соңгы чирегендә ел саен дистәләрчә казах, башкорт, үзбәк, азәрбайҗан әдәбияты, нигездә, фольклор әсәрләре басылган.

XX гасыр башында төрки телләрдәге китаплар бастыру тагын да арткан.

Төрки халыклар әдәбиятыннан татар матбагаларында басылган китаплар арасында казах әдәбияты һәм фольклоры беренче урында тора, башкорт әдәбияты һәм халык авыз иҗаты әсәрләре икенче урынны били. Шулай ук кыргыз, үзбәк, Кырым татарлары, нугай, азәрбайҗан һәм бүтән халыкларның фольклор үрнәкләре, әдәбияты әсәрләре үз телләрендә яисә тәрҗемә итеп бастырылган.

Казах телендәге китаплар иң башта Казанда басылган булса, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында Оренбург, Әстерхан һәм Уфада да чыккан. 1831 елдан алып 1917 елга кадәр казах телендә чыккан 509 басманың тиражы 2,5 миллион данәгә якын булган. Болардан 13 китап кына казна исәбеннән һәм рус наширләре тарафыннан бастырылган. Ә калган басмаларның күпчелеге татар наширләре һәм өлешчә (100 гә якын китап) казах наширләре хисабыннан чыгарылган.

Әлифбалар һәм дәреслекләр

Әлифбалар. Тарихтан мәгълүм булганча, Идел буе Болгар дәүләтендә, ягъни X–XIII гасырларда ук, мәктәп-мәдрәсәләр эшләгән. Дин, әдәбият, тарих, фәлсәфә һәм медицина фәннәре буенча хезмәтләр язылып, кулъязма китаплар рәвешендә таралган.

Халкыбызның беренче әлифбалары Идел буе Болгар дәүләте мәктәп һәм мәдрәсәләрендә төзелә башлый. Алар Алтын Урда һәм Казан ханлыгы халыкларында соңрак та файдаланыла һәм даими камилләштерелә. Киң таралган әлифбалар арасында XVIII йөзнең икенче яртысында Мортаза Котлыгыш улы белән Ишнияз бине Ширнияз тарафыннан язылган кулъязма әлифбалар билгеле.

Сакланып калган беренче басма әлифбалар XIX гасыр башы мәктәпләре өчен чыгарылган. 1802 елда Казан университеты типографиясендә 11 мең данә тираж белән Мортаза Котлыгыш улының «Шәраител-иман» («Иман шарты») әлифбасы басыла. Бу китап – иң күп басылган татар әлифбаларының берсе. Йөз егерме алты ел дәвамында (1802–1928) аның 100 гә якын басмасы дөнья күргән. Аннан соңгы заманнарда укырга-язарга өйрәтү, шул исәптән җәдитчә мәдрәсәләр өчен Галимҗан Барудиның «Сәвад хан» (1891), Мөхәммәдвәли Мөхәммәдрәхим әл-Чистайиның «Иказел-вилдан» («Балаларны уяту», 1891), Әхмәтһади Максудиның «Мөгаллиме әүвәл» («Беренче дәреслек», 1892), «Мөгаллиме сани» («Икенче дәреслек», 1902) әлифба-дәреслекләре төзеп чыгарыла. Ә. Максуди әлифбалары 1892–1917 елларда күп тапкырлар нәшер ителә һәм Россиянең барлык төрки телле халыклары мәктәпләрендә кулланыла. XIX йөз ахырында Имаметдин Сәйфуллинның «Яңа әлифба» (1892), Шакирҗан Таһириның «Бәдъ әт-тәгълим: мөкәммәл әлифба» («Башлангыч белем бирү өчен тулы әлифба», 1893) исемле беренче рәсемле әлифбалары дөнья күрә. Күп әлифбаларда математикадан башлангыч мәгълүмат бирелгән бүлек – әбҗәд (саннарны гарәп хәрефләре белән билгеләү) аерылып торган. Алар арасында Каюм Насыйриның «Иҗек: ибтидаи сабакка шөругъ кыйлгучы балаларга иҗек танытмак өчен бер тәҗрибәдер» (1895), «Иршадел-хибба илә тәгълимел-әлифба» (1891) китаплары бар.

Татар әлифбаларының бер төре – рус гимназияләрендә укучыларны татар теленә өйрәтү өчен уку ярдәмлекләре. 1778 елда Сәгыйть Хәлфин тарафыннан «Хәреф вә иҗекләре тулы тасвирланган татар теле әлифбасы» нәшер ителә. 1787 елда аның «Әлифбаи татар» дәреслеге басыла. 1809 елда Ибраһим Хәлфиннең «Гарәп укуы кагыйдәләре белән татар теленең алфавиты һәм грамматикасы» дәреслеге, 1859 елда Габдүш Баһаповның «Мөгаллиме әүвәл фи тәгъ-

лим лисанел-гарәп вәл-фарси вәт-татари» дәреслеге, 1887 елда Мирсалих Бикчуринның «Татарларга русча, русларга татарча сөйләшергә һәм үзлегеннән укырга өйрәткеч» уку ярдәмлеге дөнья күрә. XIX йөз ахыры – XX йөз башында мәктәптә укыту системасын үзгәртеп кору, ягъни «җәдитчә укыту»га күчү сәбәпле, яңа төр дәреслекләр, шул исәптән укытуның аваз методына нигезләнгән әлифбалар барлыкка килә. 1893 елда Мөхәммәтзакир Ишмөхәммәтовның «Берьюлы уку-язу» әлифбасы, 1900 елда «Әлифбага йитәкче» дигән уку ярдәмлеге, 1908 елда Хәбибрахман Зәбиринең «Рәсемле әлифба»сы басыла. XIX гасырның икенче яртысыннан керәшен татарлары өчен әлифбалар булдырыла, алар педагог-миссионер Н. И. Ильминский тарафыннан кириллица нигезендә төзелә.

Атаклы педагог Мөхетдин Корбангалиевнең «Татар әлифбасы» 1912–1918 еллар дәвамында 7 тапкыр, шушы һәм башка исемдәге әлифбалары 1945 елга кадәр тагын 20 тапкыр басылып чыга.

Гомуми башлангыч белем бирүне гамәлгә кертү һәм олыларны укырга-язарга өйрәтү өчен татар әлифбалары төзү 1920 еллар ахыры – 1930 еллар башында аеруча киң колач ала. Г. Шәрәф һәм Ш. Алексеевның «Беренче адым» (1923), «Якты юл» (1926), «Яңа тормыш» (1928) әлифбалары нәшер ителә. Латин графикасына күчү уңае белән, Гыймад Нугайбәк һәм Мөхәммәтхан Фазлуллинның «Яңа әлифба»сы (1926) нәшер ителә.

Бөек Ватан сугышыннан соңгы елларда татар мәктәпләрендә Габбас Сәйфуллин әлифбасы укытыла. 1965 елдан башлап Рәмзия Вәлитова белән Сәләй Вәгыйзов әлифбасы гамәлгә керә. Бу авторларның ике вариантагы әлифбалары соңгы вакыткача 60 тан артык басмада дөнья күрде. Рус телле балалар өчен 1990 еллардан башлап аерым әлифбалар чыгарыла, мәсәлән, Фәрит Йосыпов белән Лениза Новикова төзегән Әлифба (1994, 1998). Хәзер мәктәпләрдә Альбина Нурмөхәммәтова, Зәйтүнә Ризванова, Клара Зарипова Әлифбасы (2002, 2007), Фирдәвес Гарифуллина, Илсөяр Мияссарова, Рәсимә Шәмсетдинова Әлифбалары (2011, 2012), Рәдинә Ягъфәрова Әлифбасы (2012), балалар бакчаларында Лилия Гыйлаҗева белән Гүзәл Нәбиуллина төзегән, дүрт кисәктән торган «Нәниләр өчен әлифба» (2011, 2012), Резеда Шәехованың «Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы» (2011) кулланыла.

Җәмил Зәйнуллинның гарәп язуын үзлегеннән өйрәнүчеләр өчен төзелгән, берничә тапкыр басылган (1989, 1991, 1993) әлифбалары, Вахит Хаковның латин графикасында уку һәм язу күнекмәләре бирелгән «Телен белгән ил ачар» җыентыгы (1993), югарыда телгә алынган С. Вәгыйзов белән Р. Вәлитованың «Латин графикасы нигезендә әлифба» дип аталган эксперименталь уку ярдәмлеге (2000, 2002) бар. Соңгы елларда әлифбалар төзүдә яңа технологияләр кулланыла башлады: Т. Шакирова төзегән «Нәниләргә әлифба» китабы (2012) авазларны тавышлы өйрәткеч белән, Р. Бикташев, З. Җамалетдинова, А. Хәкимуллин, Ә. Сингатуллин эшләгән «Әлифба» интерактив дәреслеге мультимедиа басма (2012) рәвешендә дөнья күрде.

Р. Вәлитова белән С. Вәгыйзов озак еллар хезмәт куйган Арча педагогия көллиятендә 1999 елдан Әлифба музее эшли, биредә татар әлифбалары тарихы киң яктыртылу белән берәттән йөзләгән башка телләрдәге әлифба китаплары да урын алган.

Дәреслекләр. Татар мәктәп-мәдрәсәләрендә гасырлар дәвамында кулъязма дәреслекләр кулланылган. Искечә (кадими) татар уку йортларында «Иман шарты», Коръән, Һәфтияк, «Гакаид», «Фәраиз», «Кыйссаи Йосыф», «Бәдәвам», «Кыйссасел-әнбия», «Мөхәммәдия», «Нәсихәтес-салихин», «Сөбател-гаҗизин» һ. б. күптөрле китаплар дәреслек буларак файдаланылган. Кадими татар мәктәп-мәдрәсәләрендә уку-укыту системасы, нигездә, Бохара һәм Урта Азиянең башка калаларындагы уку йортлары үрнәгендә алып барылган. Дагстанда белем алган татар шәкертләре татар уку йортларында да андагы үрнәк буенча укытып, андагы дәреслекләрне кулланганнар. XIX гасыр урталарына кадәр Бохара якларында белем алучылар күп булган. Бу, әлбәттә, дәреслекләрнең кулланылуында да чагылган. Кадими уку йортларында ислам дине һәм шәригать өйрәтмәләре, гарәп теле, фәлсәфә, мантыйк, әхлак, хисап һ. б. фәннәр тирәнтен өйрәнелгән. Дәреслекләрнең күпчелеге гарәп телендә булып, төрки-татар һәм фарсы телләрендәгеләре дә кулланылган.

Кадими мәдрәсәләрдә мөселман дөньясының төрле дәвер һәм төрле ил-дәүләт галимнәре язган фәнни китаплар гамәлдә булган. Ислам мәдәниятенең югары үсеш чорында, ягъни Урта гасырларда иҗат ителгән хезмәтләр аеруча күп кулланылган. Татар мәктәп-мәдрәсәләрендә XII–XVI гасырларда гарәп һәм фарсы телләрендә язылган дәреслекләр белән бергә XIII–XVIII гасырларда төрки-татар телендә иҗат ителгән әдәбият һәм фәнни әсәрләр файдаланылган.

Иске төр мәдрәсәләрдә дәреслек сыйфатында кулланылган китаплар, матбагалар эшли башлагач, даими басылып торган. Казанда беренче типография ачылгач та, анда иң элек басылган китапларның дәреслекләр булуы игътибарга лаек. Йөз ел эчендә кайбер дәреслекләр кабат-кабат басылган. Шуңа карамастан татарларда XX гасыр башына кадәр кулъязма китапларның да күчермәләре кулланылуы тукталмаган.

Россия Мәгариф министрлыгы, татар уку йортларына бернинди ярдәм күрсәтмәсә дә,

XIX гасырдан башлап мөселман мәктәп-мәдрәсәләре эшенә тыкшына башлаган. 1892 елда Мәгариф министрлыгы мөселман уку йортларында кулъязма китаплар һәм чит илләрдән китерелгән дәреслекләр куллануны тыйган карар чыгарган. Бары тик цензура рөхсәте белән басылган китаплардан гына файдаланырга яравы белдерелгән. Хәтта тыелган китапларны мәктәп-мәдрәсәләрдән җыеп алу өчен Казаннан төрле өязләргә жандармнар җибәрелгән. Татар халкының кискен каршылык күрсәтүе нәтиҗәсендә, бу карар 1894 елда гамәлдән чыгарылган.

XIX гасыр ахырында, бигрәк тә XX гасыр башында яңача (җәдитчә) укыту ысулы киң таралыш алган. Җәдит мәктәпләрендә дөньяви һәм иҗтимагый фәннәр укыту күбәйгән. Татар дәреслекләренең төрләре һәм тематикасы гаять арткан, эчтәлекләре баеган һәм сыйфатлары камилләшкән. XIX гасырда татар галимнәре, әдипләре һәм педагоглары хисап (арифметика), тарих, география, дин дәресләре һәм бүтән фәннәр буенча яңа дәреслекләр язып бастырганнар. Мәсәлән, педагог һәм әдип Каюм Насыйри хисап, география, тел белеме, тәрбия-әхлак буенча дәреслекләр язган. Шулай ук Галимҗан Баруди, Ризаэддин Фәхретдин күпсанлы дәреслек китаплары бастырганнар. Дини һәм гуманитар белемнәргә караганнары да, төгәл фәннәр буенча да күп санда дәреслекләр дөнья күргән.

Җәдит мәктәп-мәдрәсәләренең мөгаллимнәре белән берәттән аларда кулланылган дәреслекләр һәм аларның авторлары патша хөкүмәте тарафыннан даими эзәрлекләүгә дучар ителгән. Татар дәреслекләре ныклы цензура күзәтүенә алынган.

1909 елда татар телендә чыккан 311 исемдәге китапның 70 е дәреслекләр булуы бу төр басмаларның нәшер ителү дәрәҗәсен күзалларга мөмкинлек бирә.

1891–1917 еллар арасында уку йортлары өчен басылып чыккан гуманитар фәннәр буенча татар дәреслекләренең хисабы 740 исемдә булып, аларның гомуми тиражы 5 миллионнан арткан. Боларның 526 исемдәгесе дини фәннәр буенча, 206 исемдәгесе әдәбият һәм уку китаплары, 118 исемдәгесе татар һәм рус телләре дәреслекләре, 102 китап әдәп-әхлак буенча, 41 китап татар халкы һәм гомуми тарих дәреслекләре булган. Китапларның бер өлеше шушы еллар эчендә берничә басмада дөнья күргән. Гуманитар фәннәр буенча татарча дәреслекләрнең күпчелеге Казанда Кәримевләр матбагасында басылган. Һәр дәреслек уртача 8 мең данә тираж белән чыккан. Аннан кала дәреслекләр бастыру буенча әһәмиятле урын тоткан «Мәгариф» нәшриятында һәр китап уртача 4400 данә тираж белән басылган. «Милләт» матбагасы дәреслекләр нәшер итү буенча өченче урында булып, анда басылган китаплар уртача 6600 данә тираж белән чыккан. Шулай ук бүтән басмаханәләрдә дә дәреслекләр чыгып торган.

Совет хакимияте урнашкач, халык мәгарифен үстерүгә зур игътибар бирелә. Уку-укыту һәм мәктәп системасының яңача корылуы белән бәйле рәвештә яңа дәреслекләр нәшер итү гамәлгә ашырыла. Бу эш белән башта Госиздатның Казан бүлеге, аннары Татгосиздат («Татгиз», «Татиздат» атамалары белән дә йөртелгән) шөгыльләнә, бу соңгысы озак еллар дәвамында дәреслекләр нәшер итүнең төп үзәге булып тора. Уку-укыту китапларын чыгару елдан-ел артып, аларның тираж саны да үсә бара. 1920 еллар башында кайбер дәреслекләр 25–30 мең нөсхәдә чыкса, 1927 елга инде ул 50–300 меңгә җитә. Мәктәп программасындагы фәннәрне туган телдә укытуны тәэмин итү максатында татарча оригиналь дәреслекләр язу эшенә белгеч-авторлар җәлеп ителә. Дәреслекләрдәге текстлар иллюстрацияләр, атласлар, портретлар белән баетыла, китап тышлыклары башта юка булса, 1926–1927 еллардан башлап алар калын катыргы тышлыкларда чыгарыла.

1920 елларның ахырында татар язуын гарәп графикасыннан латин графикасына, 1939 елда латиннан кириллицага күчерү бөтен нәшрият-матбага эшендә зур үзгәрешләр тудырып, дәреслекләр нәшер итүдә дә өстәмә кыенлыклар китереп чыгара. Шуңа карамастан 1928–1939 елларда бөтен фәннәр буенча диярлек татарча дәреслекләр латин хәрефләре белән нәшер ителгән.

Бөек Ватан сугышы чорында дәреслекләр һәм педагогик хезмәтләр бастыруның кимүе күзәтелә. Ул елларда барлыгы 243 дәреслек 6 миллионнан артык гомуми тираж белән басылып чыга. Галим Тәлгать Насыйров тикшеренүләренә караганда, дәреслекләрнең гомуми тиражы бары тик 1950 еллар башында гына сугышка кадәрге саннар белән тәңгәлләшә.

Дәреслекләр нәшер итү аннан соңгы чорда да Татарстан китап нәшриятының төп вазифаларыннан берсе булды һәм ул уңышлы үтәлеп килде.

1991–2009 елларда дәреслекләр һәм уку ярдәмлекләре нәшер итү белән, нигездә, «Мәгариф» милли нәшрияты шөгыльләнде. Шулай ук бу өлкәдә «Хәтер» нәшриятының эшчәнлеге дә игътибарга лаек.

Хәзерге заманда Татарстан нәшриятлары әзерләгән дәреслекләрне матбагаларда бастыру өр-яңа технологияләр кулланып башкарыла, алар сыйфат һәм эчтәлек ягыннан тагын да камилләшә бара.

Балалар китабы

Халыкның рухи тормышында балалар әдәбиятының әһәмияте аеруча зур, чөнки тарихта шулай кабул ителгән ки: гаилә, мәктәп, ә соңрак гаммәви мәгълүмат чаралары кебек традицион иҗтимагый институтлар белән берәттән аңа да бик җитди тәрбияви бурычлар йөкләнә.

1917 елгы революциягә кадәрге татар балалар китабына карата да шушы ук сүзләрне хаклы рәвештә әйтә алабыз – ул да мөһим педагогик, әхлакый-этик, мәдәни вазифаларны үтәгән.

Татар балалары өчен махсус нәшер ителгән басмаларны, татар авторларының оригинал телендә һәм башка халык авторларының татар теленә тәрҗемәдә басылган, эчтәлеге, материалны җиткерү хасияте, теле белән балаларга яраклы, аларга тәрбия һәм гыйлем бирүгә хезмәт итә торган басмаларын татар балалар китабы дип санарга кирәк. Татар балалар әдәбияты барлыкка килү тарихы гасырлар белән билгеләнә. Элек балаларны уку-язуга өйрәтү өчен алар җиңел файдалана алырлык кызыклы китаплар сайланган һәм тәкъдим ителгән. Өлкәннәр өчен булган милли әдәбият, фольклор әсәрләре озак вакытлар балаларга да хезмәт иткән. Хуҗа Насретдин мәзәкләре, «Мең дә бер кичә» әкиятләре, «Сак-Сок», «Йосыф-Зөләйха», «Таһир-Зөһрә», «Кисекбаш», «Бүз егет» һәм мавыктыргыч сюжетлы башка күп кенә кыйсса-бәетләр кулъязма һәм басма вариантларда татар балалары тарафыннан бик яратып укылганнар.

Күренекле татар мәгърифәтчесе, педагог Каюм Насыйриның 1860 елда нәшер ителгән «Буш вакыт» әсәре балалар өчен махсус язылган һәм басылып чыккан беренче татар балалар китабы дип карала. Шул рәвешчә балаларга атап чыгарылган бу беренче фәнни-популяр басма татар милли китап матбагачылыгындагы яңа бер мөстәкыйль юнәлешне – балалар өчен китаплар нәшер итүне башлап җибәрә.

Милли китап басу эшендә мөһим борылыш китереп чыгарган 1905 елгы революциядән соң балалар китабының репертуары шактый киңәя. Аңа кадәр балалар китабының зур өлеше дини-дидактик басмалардан гыйбарәт булса, 1905 елдан башлап ул күпкә дөньявилаша. Аның дөньяви юнәлеше репертуарының, дидактик әсәрләр белән берәттән, әдәби (оригинал телендә һәм тәрҗемәдә), фәнни-танып белү һәм катнаш сыйфаттагы җыентыклар, ягъни хрестоматия китаплары белән тулылануында чагыла.

Чыгарылган китапларның күләме дә күзгә күренеп арта. 1904 елда – 15, 1908 елда 47 балалар китабы нәшер ителгән булса, 1913 елда бу сан 64 кә җитә. Октябрь революциясе алды елларында татар балалар китабы милли мәдәниятебезнең мөһим бер күренешенә әверелә.

1917–1940 еллар арасында 704 исемдәге татар балалар китабы 6 миллион 15 688 данә тираж белән басылып чыккан. Татар авторларының әсәрләрен нәшер итүдә билгеле бер күләм-дәрәҗә саклаган хәлдә, тәрҗемә китаплар бастыру шактый арта. Милли балалар китабы нәшер итүдәге бу чорны әлеге эшчәнлекнең бербөтен дәүләт системасын булдыру, милли әдәбиятны яңа шартларда үстерү, совет балалар язучылары иҗаты белән характерларга мөмкин. 1930 еллар – балалар әдәбиятының аеруча баеган дәвере.

Бөек Ватан сугышы елларында Татгосиздатта (Татарстан дәүләт нәшриятында) дөнья күргән 95 исемдәге татар балалар китапларының гомуми тиражы 843 мең данә белән исәпләнә. Сугыш авырлыкларына карамастан, татар балалар китабы үсеше акрын гына булса да дәвам итә. Балалар өчен китаплар нәшер итү сугыштан соңгы унбиш елда аеруча уңышлы бара (барлыгы 894 исемдә). Бу хәл 1946 елда нәшриятта балалар-яшүсмерләр бүлекчәсенең яңадан торгызылуы белән дә бәйле. Матур әдәбият басмалары арасында татар әдипләренең әсәрләре биләгән өлеш зурайганнан-зурая.

1960–1990 еллардагы татар балалар китабы үсешенә сыйфатлама биргәндә, аның бу чорда да Коммунистлар партиясе һәм дәүләт тарафыннан җитди игътибар объекты булып калуын, нәшриятның үзендә дә, Язучылар берлегендә дә бу юнәлештә даими эш алып барылуын әйтергә кирәк. Шул ук вакытта балалар өчен басма продукция чыгаруның гомуми күләме кимү күзәтелә: 1960 елларда 481 басма дөнья күрсә, 1970 елларда – 392, ә инде 1980 елларда 351 исемдәге китап басыла. Икътисадтагы, иҗтимагый-сәяси һәм социаль тормыштагы торгынлык күренешләре татар милли балалар китабының сыйфатына һәм эчтәлегенә дә йогынты ясый.

XX гасыр ахырында исә милли-азатлык хәрәкәтенең активлашуы, милли үзаң үсеше белән бәйле рәвештә татар китабының, шул исәптән балалар китабының да әһәмияте бик нык арта. Татар балалар китабы эчтәлек җәһәтеннән байый, бизәлеше матурая бара, полиграфик сыйфаты камилләшә. Хәзерге көндә дә татар балалар китабы нәшер итү милли китапчылыкның иң якты бер сәхифәсен тәшкил итә.

Соңгы елларда балалар өчен матур әдәбият әсәрләре белән берәттән танып белү, фәнни-популяр характердагы басмалар, уенчык, катыргы китаплар да басыла, ике-өч телле китапларга да игътибар бирелә. Татарстан китап нәшриятында 2012 елда – 32, 2013 елда 31 балалар китабы басылып чыкты.

Татар китабының эшләнеше һәм бизәлеше

Татар кулъязма китаплары, мөселман китабының бай традицияләрен сакларга тырышып, ләкин мөмкинлекләргә күрә, төрлечә сыйфатта эшләнгәннәр. Татар кулъязмалары XVI гасыр урталарына кадәр, нигездә, Шәрык илләрендә эшләнгән кәгазьгә язылган. Аннан соңгы чорда, Көнчыгышта ясалган кәгазьләрне куллану белән бергә, Европа илләреннән (Франция, Голландия һ. б.) китерелгән яхшы сыйфатлы юка кәгазьләр файдаланылган. XVII гасырның икенче яртысында Россия кәгазь базарында өстенлек тоткан голланд кәгазен татарлар да күп кулланганнар. XVIII гасырда исә башлыча Россиядә җитештерелгән калын һәм тупасрак рус кәгазьләре файдаланылган. XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башларында татар сәүдәгәрләре һәм эшкуарлары Мәмәтов, Рәхимов, Хуҗасәетов, Утәмешевләрнең кәгазь җитештерү мануфактуралары да эшләгән. Алар кәгазьне, нигездә, мөселман осталары үрнәгендә җитештергәннәр. XIX гасыр дәвамында күбесенчә рус кәгазьләре гамәлдә булса да, *татарлар мамыктан ясалган* ак һәм шома Урта Азия кәгазьләрен дә үз иткәннәр.

Кулъязма китаплар камыш һәм каурый каләм белән язылган. Язу каралары төрле үсемлекләр һәм аларның тамырлары, агач кайрылары, корым һәм башка матдәләрдән әзерләнгән. Кулъязма китапларның төп текстында караңгы төстәге бертөрле язу карасы файдаланылган булса, бүлек атамалары яисә аерым гыйбарәләр еш кына кызыл төс, кайчагында яшел, зәңгәр һәм сары төсләр белән язылган. Биттәге текстны каймалаган сызыкча-рамкалар да еш кына шундый ук *төсләрдәге* кара белән сызылган.

Китап тексты башта аерым дәфтәрләргә язылып, тулаем күчерелеп беткәч, китап итеп төпләнгән. Төпләмендәге төрле дәфтәрләре *төрле* кеше кулы белән язылган китаплар да очрый. Бигрәк тә күләмле әсәрләр берничә кеше яисә бер төркем шәкертләр тарафыннан өмә ясап күчерелгән. Мәсәлән, Шиһабетдин Мәрҗанинең Бохарада укыган вакытында кайбер китапларны 10–15 шәкерттән күчертеп яздырганлыгы мәгълүм.

Татар китапларында гарәп язуының күп төрләре, алай да күпчелек очракта берничә язу төре файдаланылган. Коръән китабы бары тик нәсех стиле белән башкарылса, башка әсәрләр нәсех һәм нәстәгълыкъ төрләре белән язылганнар. Татар кулъязмаларының нәстәгълыкъка якын, аермалырак бер язу төрен фәнни әдәбиятта «татар тәгълыкы» дип тә йөртү хас.

Китап тышлыклары, юка тактадан яисә катыргыдан ясалып, тулаем күн белән тарттырып эшләнгән. Күн еш кына тышлыкның төп ягында, читләрендә һәм почмакларында гына кулланылган. Фәкыйрьрәк шәкертләр исә тышлык өчен иске китап битләрен яки кирәкмәгән кәгазьләрне катыргы рәвешендә ябыштырып, аның өстеннән тукыма белән тарттырып куйганнар. Татар кулъязма китаплары бәрхет, ефәк, атлас, киҗе-мамык, алача һ. б. төр тукымалар белән тышланган. Коръән һәм башка затлы китапларны, төп тышлыгы нинди булуына карамастан, тагын бер кат тукыма белән тышлау гадәте күзәтелгән. Андый тукымаларга алтын-көмеш җепләр белән бизәкләр дә чигелгән. Күн тышлыкларга төрле бизәк-орнаментлар батырып төшергәннәр. Татар осталары тарафыннан Урта Азиядә ясалган тышлыкларда, шундагы китап традициясе үрнәгендә, медальон сыман бизәкле рәсем эчендә китап тышлаучының (суххәф) исеме дә языла торган булган. Бохара һәм Сәмәрканд якларында язылган татар кулъязмалары андагы китапларга охшаш булса, Төркиядә яисә Дагстанда белем алган татар шәкертләре күчереп язган һәм төпләгән китаплар шул төбәктәгеләр үрнәгендә эшләнгән. Мондый күренеш күп мисаллар белән раслана. Татар шәкертләре һәм муллаларының төп ватаннарыннан читтә вакытларында һәм илгә кайткач күчергән китап текстларында күрсәтелгән «Болгари», «Казани» һәм бүтән шундый нисбәләре генә татар кешесе тарафыннан эшләнгән китап икәнлеген белдерә. XIX гасыр татар кулъязмалары тышлыкларында «суххәф Мөхәммәдгали Болгари» исеме – хәзергәчә күп сакланганнарның берсе.

Кулъязма китапларның беренче битенә еш кына бизәкләр ясалган, әлеге башлам өлеше «гонван» дип аталган. Сәнгать белгечләре гонванны чәчәк бәйләме белән тиңлиләр. Күпчелек китапларның текстлары төрле төсләрдәге рамкаларга алынган. Дини һәм фәнни китапларның тексты бер биттә күп урын алмыйча, битнең читләре искәрмәләр, аңлатма һәм өстәмәләр язу өчен махсус буш калдырылган. Күләмле шигъри әсәрләр бер биттә, гадәттә, ике баганада язылган. Алар еш кына сызыклар белән, ә кайчакта бизәк-орнаментлар белән бүленгән.

Татар-мөселман кулъязма китапларының титул битләре булмаган. Әсәрнең авторы һәм исеме текст башланган биттә күрсәтелгән яисә текстның бетем өлешендә – колофонда әйтелгән. Мөселман китапчылыгына хас булганча, колофонда, гадәттә, тулы мәгълүмат: китапның исеме, авторы, әсәрнең язылу елы, кем тарафыннан, кайда һәм кайчан күчерелүе күрсәтелгән. Татар кулъязмаларында бу кагыйдә һәрвакытта да сакланып җитмәгән.

Халкыбызның иҗтимагый-сәяси хәле белән турыдан-туры бәйле рәвештә татар кулъязма китабының сәнгати бизәлеше XVI гасырның урталарыннан алып үз үсешендә тоткарлык кичергән. Шулай да гаять гүзәл аерым кулъязма истәлекләр дә сакланып калган. Гасырлар дәвамында колониаль изелүдә яшәгән татар халкы-

ның кулъязма китабы, мөстәкыйль дәүләтләрдә яшәгән мөселман төрки халыкларның китаплары белән чагыштырганда бизәлеш сыйфаты ягыннан калышса да, мәгънәви һәм сан җәһәтеннән бирешмәгән. Татар дәүләтләре туздырылгач, рәсми китапханәләргә, мөселман китап базарына, затлы-зиннәтле китаплар күчерүгә ихтыяҗ бетә диярлек. Дини һәм милли изү аркасында кулъязма китапларны сәнгати яктан нәфисләп эшләүгә зарурият тә, мөмкинлек тә калмый.

Җанлы затларның рәсемнәрен сурәтләү ислам дине тарафыннан тыелганга, татар кулъязма китапларында андый рәсемнәр ясалмаган. Китапларда күбесенчә үсемлек һәм чәчәк сыман бизәкләр, кайчагында бина-корылмалар рәсемнәре һәм башка төрле сурәтләр ясалган.

Рәсем ясау сәләтенә ия осталар гарәп язуының каллиграфик үзенчәлекләрен тирәнтен үзләштергәннәр. XVII–XIX гасырларда нәфис язу белән китаплар күчергән осталардан Морадым бине Ибраһим, Нияз бине Хәйдәр, Фәхретдин бине Ибраһим, Сәгыйть бине Хәмит, Таҗетдин Ялчыгол, Хәсән бине Вәлит, Камалетдин бине Җамалетдин, Каюм Насыйри кебек татар хаттатларының исемнәре билгеле.

Кулдан күчереп язылган китапларның зурлыгына килгәндә, алар төрле форматта: миниатюр нөсхәләрдән алып хәзерге журналлардан да зуррак рәвештәгеләре булган. Формат төрлелеге язма китапларның эчтәлек күләме һәм әһәмиятенә карап билгеләнгән. Миниатюр татар кулъязмаларының игътибарга лаек бер үрнәге Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә саклана. Ул – иңе – 5 см, буе – 4,4 см һәм калынлыгы 2,3 см тәшкил иткән, тексты каурый каләм белән язылган һәм күн белән тышланып төпләнгән ядкяр. Дини эчтәлекле һәм зур күләмле әсәрләрне, гадәттә, олы форматтагы кәгазьгә язганнар. Фольклор һәм шигъри әсәрләр күбесенчә 11x17 см форматлы кәгазьдә, ә кулъязма китапларның иң күп кулланылган оптималь зурлыгы, гомумиләштереп билгеләгәндә, 17x22 см үлчәмендә булган.

Татар басма китаплары күпгасырлык кулъязма китап традицияләрендә үстерелгән. XVIII гасырда Петербургта Екатерина II фәрманы белән нәшер ителгән Коръәннәр И. Шнор типографиясе өчен галим-мулла Госман Исмәгыйлев әзерләгән ике төрле кегльдәге шрифтлар белән басылган. Гарәп хәрефләре белән төрки-татар китапларын бастыруда Исмәгыйлев шрифтлары йөз елдан артык кулланылган.

XIX гасыр башында Казанда ачылган типографияләрдә басылган татар китаплары бизәлешендә элекке кулъязма китаплар йогынтысы аермачык күренеп тора. Татар наширләре бастырган китапларда 1830 елга кадәр титул битләре булмаган. Бөтен төр китапларның да тексты башланган беренче битендә «Бисмилләһир-рахмәнир-рахим» сүзләре язылган. Бу гыйбарә еш кына зиннәтле гонван эченә урнаштырылган. Гонван өлешендә кайчакта китапның исеме дә күрсәтелгән. Һәр биттәге текст бер яки ике катлы сызык-рамка эчендә яки рамкасыз гына бирелгән. Китапның авторы һәм исеме, гадәттә, текст башында әйтелгән. Ә анда белдерелмәсә, китап ахырында, текстның соңгы битендәге бетем өлешендә – колофонда – тулы мәгълүмат урын алган. Анда китапның авторы, исеме, булса – тәрҗемәчесе, кайсы елда, кайда бастырылуы һәм кем тарафыннан нәшер ителүе язылган, цензура тарафыннан рөхсәт бирелгән датасы күрсәтелгән. Еш кына цензорның исем-фамилиясе дә әйтелгән.

Лотфулла бине Гатаулла, Гали Мәхмүдов кебек татар хаттатлары кулъязма һәм литографик басмалар өчен шәркый бизәкләр ясаучы осталар буларак танылганнар. Матбага хуҗасы Л. Шевиц үз карамагында һәм шулай ук университет басмаханәсендә нәшер ителгән китаплар өчен бизәкләр ую (гравёрлау) белән дә шөгыльләнгән.

XIX гасырның икенче яртысында китап бастыру бәяләренең арзанаюы татар китапларының начар кәгазьдә, юка тышлык белән чыгарылуына китергән. Шуңа күрә китапларны бизәүгә игътибар аз булган, басмалар бер үк төрле шрифтта һәм бер үк төрле трафарет бизәкләр белән чыккан.

Казан шәһәрендәге типографияләрдә басылган татар-мөселман китаплары Шәрык сәнгатенең бай традицияләрен саклау белән бергә Көнбатыш полиграфия казанышларын куллану җәһәтеннән үзенчәлекле урын биләгән.

Татар китапларын XIX гасыр ахырында рәсемнәр һәм иллюстрацияләр белән бизи башлаганнар. Бертуган Кәримевләр беренчеләрдән булып гарәп шрифтларын төрләндерү һәм матурлауга зур өлеш керткәннәр, китапларны рәсемнәр белән бизәүгә әһәмият биргәннәр. Рәсемнәр, билгеле булганча, әсәрнең эчтәлеген тулырак ачып, аны җанландыра һәм укучының кабул итүенә уңай тәэсир итә. Кәримевләр матбагасының китап бизәлешенә үзгәрешләр кертүе Казандагы матбагалар арасында конкуренциягә һәм шуның белән берлектә татар китабының сан ягыннан да, сыйфат җәһәтеннән дә үсешенә этәргән.

XX гасыр башында Казан типографияләре осталары гарәп шрифтының нәфис хәрефләрен әзерлиләр. Шул ук чорда татар матбугатының зур үсеш алуы белән бергә милли рәссамнарга ихтыяҗ туа. XX гасыр башында татар китаплары бизәлешенә Госман Гомәров, Габбас Табулдиев, А. Комаров, Ф. Быков, Оренбург рәссамы Романов өлеш керткән. Бу чорда китап бизәлешендә типографияләрдә булган әзер нәкыш клишеларын еш файдаланганнар.

XX гасыр башында татар китабы бизәлешенә зур үзгәрешләр һәм яңалыклар кертелгән. Төрле шрифтлар һәм рәсемнәр киң кулланыла башлаган. Китап тышлыклары, титул битләре һәм текстлары яңача бизәлеп, сәнгати эшләнеш ягыннан үрнәк басмалар дөнья күргән. Бу чорда фәнни-популяр эчтәлектәге татар китапларының бөтенесе дә диярлек рәсемнәр белән басылган. Мәктәп-мәдрәсә дәреслекләре һәм балалар өчен чыгарылган китапларны иллюстрацияләүгә дә зур әһәмият бирелгән. Дәреслекләрдә һәм фәнни-популяр китапларда, нигездә, рус китапларында басылган рәсемнәр урын алган. Рус әдипләре А. С. Пушкин, Н. В. Гоголь, И. С. Тургенев, А. П. Чеховларның юбилейлары уңаеннан татарчага тәрҗемә ителгән әсәрләре авторларның портретлары белән чыгарылган.

Рәсемнәрнең күпчелеге ике төстә (аклы-каралы) булып, 1910 елларда бүтән төсләр кулланып басылган китаплар да күренә башлаган. Бу чорда татар рәссам-иллюстраторлары да эшли башлаган. Алар башлыча балалар китабын бизәү белән шөгыльләнгән.

Китапларның сәнгати бизәлешен камилләштерү белән бергә титул битләрен унификацияләүгә дә омтылыш ясалган. XX гасыр башында титул битендә әсәрнең исеме, аның авторы, тәрҗемәчесе, басылган урыны һәм елы, типографиясе һәм нашире, кабатлап басылган очракта ничәнче басма булуы, сату бәясе күрсәтелгән. Кайбер әсәрләрнең кыскача эчтәлеге – аннотациясе дә – титул битендә һәм тышлыкта бирелгән.

1905 елдан соң татар басмалары аерым сериялә р рәвешендә дә нәшер ителгән. Мәсәлән, «Шигырьләр көтепханәсе», «Әдәбият мәҗмугасы», «Театр мәҗмугасы», «Фән һәм техника», «Балалар көтепханәсе» һ. б. дәвамлы басма сериялә р дөнья күргән. Аларның бизәлешләрендә, сериялә ргә хас булганча, бертөрле стиль сакланган.

Татар телендәге вакытлы матбугат барлыкка килгәч, кайбер газета һәм журналлар кушымта рәвешендә төрле җыентыклар, брошюралар һәм китаплар бастырып, үз абунәчеләренә бушлай җибәргәннәр.

XX гасыр башы татар китабы тарихына аеруча зур өлеш керткән шәхесләрнең берсе – И. Н. Харитонов. Аның эшчәнлеге халык яратып укый торган әсәрләрне күп бастыруы белән генә түгел, татар полиграфиясен үстерүгә керткән яңалыклары белән дә аерылып тора. Ул татар шрифтларын камилләштерүдә реформатор, китапны сәнгати һәм полиграфик яктан баету өлкәсендә беренче матбагачы булган. Яңа татар шрифтлары ясау өчен Харитонов Галиәсгар Камалга мөрәҗәгать иткән. Чөнки әдип һәм нашир Г. Камал оста каллиграф та булган. Ул татар шрифтларының яңача рәсемнәрен эшләп биргән, гравёр һәм хәреф коючы Ибраһим Юзиев, шул рәсемнәргә таянып, яңа шрифт калыплары әзерләгән. Бу шрифтлар соңыннан «Харитонов хәрефләре» дип йөртелгән. Хәреф-шрифтлар реформасыннан соң Харитонов типографиясендә басылган китапларның полиграфик сыйфаты яхшырган. Шуның нәтиҗәсендә И. Н. Харитонов китаплары бөтен дөньяда дан казанган. Аның матбагасында матур хәрефләр белән чыккан китаплар медальләр белән бүләкләнгән, ә 1909 елда Халыкара китап күргәзмәсендә Харитонов типографиясендә чыккан китаплар иң югары бүләккә – алтын медальгә лаек булган.

Харитонов керткән яңалыклар һәм үзгәрешләр тәэсирендә башка матбагалар да шрифтларын яңартырга мәҗбүр булалар. Шул вакыттан китап сәнгате нигездән үзгәрә башлый. Татар китаплары басу белән шөгыльләнгән типографияләрнең соравы буенча, Харитонов сату өчен шрифтлар хәзерли. Аның хәреф кою цехларында ясалган шрифтлар Россиянең төрле төбәкләренә таралган.

Гомумән, хәреф җыеп китап бастыру өчен гарәп шрифтлары шактый җайсыз булган. Аның төп сәбәбе – гарәп хәрефләренең язылышы күптөрле булу һәм моңа бәйле рәвештә типография хәрефләренең дә ишәюе. XX гасыр башында Мөхәммәт Идрисов полиграфия өлкәсендә гарәп-төрки шрифтларын унификацияләүне башкарган. Нәтиҗәдә китаплар бастырганда текстны җыю җиңелрәк һәм тизрәк эшләнә, шул сәбәпле басмаларның үзкыйммәте дә арзаная.

Мөхәммәт Идрисовның шрифтларны үзгәртеп, басма өчен җайлаштырудагы ачышлары үз чорында революцион казанышлар белән тиң булган. Ул типографияләр өчен шрифтлар әзерләүдән тыш китаплар бизәү белән дә шөгыльләнгән (мәсәлән, Г. Тукайның «Халык моңнары» китабы), басмалар өчен төрле бизәкләр дә ясаган. Әлеге бизәкләр үз вакытында Казандагы бөтен басмаханәләрдә кулланылган. Алар 1940 елларга кадәр гамәлдә булган. Ул әзерләгән рәсемнәр буенча коелган гарәп-төрки шрифтлары Урта Азия, Казахстан һәм Кавказ типографияләренә дә җибәрелгән. СССРда гарәп-төрки хәрефләре белән уңнан сулга таба бастыра торган беренче язу машинкалары да М. Идрисов ачышлары нигезендә эшләнә. Илдә гарәп хәрефләре белән язу машинкалары җитештерелә башлагач, гарәп язуын кулланган егермедән артык халык шулардан файдаланган.

1917 елдан соң Мөхәммәт Идрисов озак вакытлар Мәскәүдәге типографияләрдә рәссам-шрифтчы һәм гравёр булып эшләгән, шушы өлкәдә педагогик хезмәт белән дә шөгыльләнгән. Ул – бөтен гомерен милли китапчылык эшенә һәм полиграфия өлкәсенә багышлаган сирәк шәхесләрнең берсе.

Идрисов шрифтларын һәм полиграфиядә ул керткән яңалыкларны XX гасырның икенче яртысында күпчелек Шәрык илләре Советлар Союзыннан алдырып кулланганнар. Шулар арасында Һиндстан, Әфганстан, Мисыр һәм Сүрия кебек эре илләр дә бар. Гарәп язуын кулланган илләр өчен СССРда эшләнгән линотип машиналарына «Нәсхи Мөхәммәт Идриси» дигән сыйфатлама язуы беркетелгән. Ягъни гарәп язуының полиграфия өчен унификацияләнгән төренә М. Идриси исеме бирелгән.

Татар китапларын нәшер итүдәге полиграфик һәм сәнгати бизәлешнең камилләшүе мәдәни һәм әдәби тормышның үсүе белән тыгыз бәйле. Бу күренешнең укучыларны китапка тагын да якынайту өчен файдасы зур булган.

1921 елда Казанда оештырылган «Игенче» нәшриятында китапларның күпчелеге рәсемнәр белән чыгарылган. Ул басмаларны бизәүдә танылган татар шрифтчысы, рәссам Мөхәммәт Идрисов актив катнашкан.

1920 елларда рәссамнар Габдрахман Бурнашев, Фаикъ Таһиров һәм Бакый Урманче да татар китаплары өчен хәреф-шрифтларны камилләштерүгә өлеш керткәннәр.

Ул чорда татар телендә чыккан китапларны бизәүдә рус рәссамнары да катнашкан. Мәсәлән, Габдулла Тукайның Павел Радимов тарафыннан русчага тәрҗемә ителеп, 1921 елда басылган «Шүрәле» һәм «Кәҗә белән Сарык» китапларының рәсемнәре Илларион Плещинский тарафыннан ясалган.

Г. Тукайның 1923 елда татар телендә дөнья күргән «Шүрәле» әкиятенә иллюстрацияләрне рәссам Бакый Урманче ясаган. Аннан соңгы елларда Б. Урманче Тукайның башка китапларын да бизәгән. Ул графика белән бергә офорт (гравюраның бер төре) техникасын да кулланган.

Татар китапларында җанлы затларның рәсемнәрен ясау тәҗрибәсе булмаганлыктан, башлангыч чорда рәсемнәрнең ясалыш техникасы һәм бизәлеш үзенчәлекләре, текст белән ярашуы камил булмаган. Ләкин бу хәл елдан-ел яхшыра барган, китап рәссамнары эзләнгәннәр һәм осталыкларын арттырганнар. Рәсемнәрдә милли типажлар һәм киемнәр, татар халкының этнографик үзенчәлекләре тулырак чагылыш тапкан. Шулай ук ул чорның идеологиясе рәсем сәнгатенә дә зур йогынты ясаган.

1920 елларда татар матбугатында һәм китаплар бизәлешендә Усман Арсланов актив эшләгән. Ул, рәсем сәнгатенең төрле ысулларына нигезләнеп, Тукай әсәрләренә күп иллюстрацияләр ясаган, гарәп каллиграфиясен дә уңышлы кулланган. Беренче совет татар рәссамнарының эшләре белән Татарстан дәүләт нәшриятында милли сәнгатьнең яңа калыбы формалашкан.

Рәссам Фаикъ Таһиров иҗаты 1920 елларда татар китабы бизәлешендә мөһим урын алып тора. Каллиграфиягә һәм рәсем ясауга сәләтле Ф. Таһиров Екатеринбург рәсем сәнгате студиясендә эшләгән һәм андагы татар матбугаты белән хезмәттәшлек иткән. 1922 елда ул Казан сәнгать-техник институтына укырга килгән. Таһиров уку белән бергә татар матбугаты өчен рәсемнәр дә ясый. Ул югары профессиональ дәрәҗәгә ирешә, гарәп шрифтларын яңача иҗат итүче һәм яңа дәвер рәссамы буларак таныла. 1924–1925 елларда татар телендә чыккан күп китаплар Фаикъ Таһиров эскизлары белән дөнья күрә. Ул макетлаган китаплар үзенчәлекле бизәлеше белән аерылып тора. Таһиров конструктивизм йогынтысы белән төрле тәҗрибәләр ясаган, ул елларда бөтен Совет иленда киң кулланылган фотомонтаж ысулының башка төрле юлларын гамәлгә ашырган. 1925–1926 елларда ул Мәскәү сәнгать-техник институтында белем алган һәм осталыгын камилләштергән. Ул үзенең иҗади сәләтен татар китабы бизәлешенә багышлаган. Мәскәүдәге Шәрык халыкларының *мәркәз нәшриятында* хезмәттәшлек иткән. Таһиров белән рәссам-график Александра Коробкова бергәләп тагын да кызыклырак сәнгати әсәрләр иҗат иткәннәр. Бу нәшрияттә башка татар рәссамнары да эшләгән.

Ф. Таһировның сәнгатьчә китап бизәлеше һәм яңа төр шрифтлар иҗат итүдәге хезмәтләре югары бәяләнгән. Аның эшләре 1925 елда Парижда узган Халыкара декоратив сәнгать күргәзмәсенә куелган. 1927 елда Мәскәүдә узган СССР халыклары сәнгате күргәзмәсендә дә Ф. Таһиров эшләре күрсәтелгән.

1923–1927 елларда Казанда керәшен татары график Дмитрий Красильников эшләгән. Ул, Пермьдәге сәнгать остаханәләрендә тәҗрибә туплаганнан соң, Казан сәнгать мәктәбенә укырга килгән. Красильников китап бизәүдә реалистик юнәлеш тарафдары буларак иҗат иткән. Китаплар өчен ул төрле күренешләрнең график рәсемнәрен һәм офорт ысулы белән эшләнгән портретлар ясаган. Д. Красильников укуын Мәскәүдә дәвам иткән һәм андагы татар матбугатында эшләгән.

Татар китабын бизәүче рәссамнар әзерләү өчен Казан сәнгать мәктәбендә Б. Урманченың да тырышлыгы белән графика бүлегенең яңадан эшли башлавы зур әһәмияткә ия. Анда укытырга литография һәм ксилография белгечләре чакырыла. Сәнгать мәктәбендә 1928–1929 елларда яшь татар рәссамнары хәзерләнгән. 1929 елда шунда укып чыккан Шакир Мөхәммәтҗанов Татгизның (Татарстан дәүләт нәшриятының) литография остаханәсендә эшләп таныла. Ул ясаган китап тышлыкларын сәнгать белгече П. М. Дульский татар матбугатының иң яхшы үрнәкләре буларак бәяләгән. 1930–1940 елларда да Мөхәм-

мәтҗанов китап рәссамы буларак эшләвен уңышлы дәвам иткән.

Татар китапларында 1930 еллар уртасына кадәр, нигездә, орнамент-шрифт бизәлеше өстенлек тоткан.

1930 еллар башыннан татар китабы бизәлешендә милли рәссамнардан Мөхәммәтша Кәримев, Гатаулла Йосыпов, Җәгъфәр Булат, Госман Мусин һ. б. эшләгән. Болар арасыннан Г. Мусинның Тукай әсәрләренә карандаш һәм тушь белән ясаган рәсемнәре киң танылган. Татар китабы бизәлешендә 1920 елларда өстенлек иткән конструктивизм һәм шартлылык стиленнән чынбарлыктагыча сурәтләүгә күчү Госман Мусин исеме белән бәйләп карала. Бу чордагы рәссамнарның күпчелеге, Казанда иҗат итә башласалар да, моннан китеп торганнар. Шул сәбәпле 1930 еллар уртасына Татарстанда профессиональ китап рәссамнарына кытлык зур була.

1935 елда рәссам Байназар Әлминовның Казанга килеп иҗат итә башлавы татар китап сәнгатен җанландырып җибәрә. Ул китап нәшриятында 35 ел дәвамында хезмәт итә. Аның эшли башлаган елларында китап сәнгатендә яңача бизәлеш этабы – еш кына аерым бит зурлыгындагы күләмле иллюстрацияләр өстенлек алган. Әлминов Тукай әкиятләре һәм шигырьләре өчен рәсемнәр ясаучы буларак танылган.

Бөек Ватан сугышы елларында китапларны сәнгати бизәү мәсьәләсе икенче планга күчә. Шулай да бу авыр чорда һәм сугыштан соң иҗат иткән рәссамнар арасында Эрнст Гельмс белән Мәхмүт Усманов исемнәрен атау мәгъкуль булыр.

1950 елларда татар китаплары өчен Харис Якупов һәм Лотфулла Фәттахов график рәсемнәр ясаганнар. Алар – татар китап графикасын эчтәлек һәм сыйфат ягыннан үстерүгә зур өлеш керткән рәссамнар. Х. Якупов, кара һәм төсле акварель белән иҗат итеп, характерларны ачып бирерлек рәсемнәр ясаган. Әкияти образларны ул аеруча бизәкле һәм зиннәтле итеп иҗат иткән, геройларны ясаганда, төсләрне оста кулланган.

Л. Фәттахов иҗаты китапның барлык элементларын бербөтен сюжет сыйфатында бизәве һәм рәсемнәренең мавыктыргыч сурәттә бирелеше белән үзенчәлекле. Татар совет әдәбиятының классик әсәрләренә Л. Фәттахов тарихи вакыйгаларның кискен сюжетларын ача торган күп планлы рәсемнәр ясаган. Ул аклы-каралы штрихлар контрастын, силуэт һәм башка төр график чаралар кулланып һәм акварель белән иҗат иткән. Аның әкиятләр өчен ясалган рәсемнәрендә юмористик башлангыч аерылып тора, ул ясаган сюжетларда һәм персонажларда комизм, халык юморы, гротеск кискенлеге ачык гәүдәләнгән.

Габдулла Тукай китапларына рәсемнәр ясаган Фәйзрахман Әминов иҗаты үзенчәлекле фантазия һәм бай сәнгати эшләнеше белән аерылып тора.

1950–1960 елларда Татарстан китап нәшриятында китап бизәлеше буенча даими эшләүче рәссамнар коллективы туплана. Киев сәнгать институтында белем алган Рәшит Төхфәтуллин, Валентин Карамышев, Степан Кульба́ка, аннан соң Таллинн сәнгать институтында белем алган Иван Язынин һәм Юрий Лысогорский, Иван Фёдоров исемендәге Львов сәнгать институтын тәмамлаган Ирина Колмогорцеваның Казанга кайтып эшләүләре алга таба үсешкә зур этәргеч була. Татарстандагы иң оста рәссам-графикларның берсе И. Язынин, Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәре», Р. Вәлитова белән С. Вәгыйзовның мәшһүр әлифбасы, «Татар халык әкиятләре» китапларын бизәп, татар китабы сәнгате үсешенә зур өлеш керткән. И. Колмогорцеваның исеме исә китап сөюче балаларга һәм яшүсмерләргә аеруча яхшы таныш, чөнки яшь буынга атап чыгарылган татар китапларының шактые аның рәсемнәре белән бизәлгән.

Казан сәнгать училищесында белем алган Иван Хантимеров, Павел Григорьев, Илдар Әхмәдиев, Леонид Анисимов, Хәбир Әхмәтҗанов, Ильяс Субаев һ. б. китап бизәүдә актив эшлиләр. Китап рәссамнары графика, акварель, офорт, линогравюра, литография кулланып һәм башка ысуллар белән иҗат итәләр.

Казанда 1960 еллар башында Мәскәү, Ленинград, Львов, Ташкент сәнгать уку йортларында махсус белем алган яңа буын китап рәссамнары иҗат итә башлый. Тавил Хаҗиәхмәтов, Эрот Зарипов, Азат Садыйков, Вацлав Зелинский, Леонид (Лотфулла) Насыйров, Герман Огородников, София Насыйрова-Әбдрәшитова кебек рәссамнарның һәрберсе үзләренә генә хас сәнгати ысул белән иҗат итәләр. Бу чорда халык сәнгате һәм фольклор үрнәкләре, милли орнаментлар һәм югары профессиональлек, бергә кушылып, тагын да киңрәк кулланыла, иллюстрацияләр зиннәтлерәк һәм затлы төсмерләргә байый. Бу хасиятләр төрлелеге танылган рәссам Т. Хаҗиәхмәтов иҗатында аеруча калку чагыла. Ул Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасына, балалар өчен татарча китапларга һәм дәреслекләргә бик күп иллюстрацияләр ясый.

1970 елларда татар китабы бизәлешенә яңа осталар килеп кушыла. Алар – Александр Туманов, Герман Трифонов, Юлия Каспина-Вургафт, Юрий Денисов, Айдар Үтәгәнов, Виталий Булатов, Борис Чукомин, Рәшит Имашев, Виктор Аршинов, Надир Әлмиев, Рушан Шәмсетдинов.

1970 еллар ахыры – 1980 еллар башында Григорий Эйдинов, Рәшит Сафиуллин, Вадим Малякин, Фәридә Хәсьянова, Рәис Шакиржанов, Иван Воробьёв, Шамил Насыйров, Зифа Мөхәммәтҗанова, Лилия Золондинова, Алсу Тимергали-

на кебек рәссамнарның китап бизәү өлкәсендәге иҗаты башлана.

Казанда китап рәссамнарының тотрыклы коллективы оешканнан соң (1950 еллар ахырыннан алып), төрле тармак китапларының сәнгати эшләнешенә бердәй әһәмият бирелә. Полиграфик базаның киңәюе, күптөсле офсет басма куллану китапларның сәнгати дәрәҗәсен күтәрү өчен зур этәргеч була. Фәнни-техник әдәбият һәм авыл хуҗалыгы буенча китапларны бизәүче Зөфәр Хөсәенов иҗаты аерым әһәмияткә ия.

Фәридә Хәсьяновaның татар балалар китабы иллюстраторы буларак иҗаты милли сәнгать тарихында аерым урын били. Ул – кырык ел гомерен шушы хезмәткә багышлаган оста. Аның рәсемнәре белән бизәлгән әлифба һәм башка дәреслекләр, әкиятләр аеруча үзенчәлекле өслүбе белән аерылып тора. Балалар өчен Ф. Хәсьянова ясаган рәсемнәргә татар милли бизәкләренең күп кулланылуы, төсләрнең нәфис ярашуы, самимилек һәм садәлек хас. Ф. Хәсьянова, Татарстан китап нәшриятының баш рәссамы булып эшләгәндә, сәнгатьнең бу төренә оста рәссамнарны җәлеп итеп, республикада китап бизәлеше сәнгатен үзенчәлекле югарылыкка күтәрүгә иреште.

1980–1990 елларда татар китабы рәссамнары сафын Илдус Әҗемов, Нияз Хаҗиәхмәтов, Рәисә Сәйфуллина, Дамир Җәләлетдинов, Юлия Щетинкина, Светлана Яркова, Зөфәр Хәкимов, Илдар Нәфиев, 2000 еллардан башлап Диләрә Нәүрузова, Алла Айсена, Светлана Ибраһимова, Заһир Хәкимов, Рөстәм Хәбибуллин, Фәридә Ризаева, Булат Гыйльванов, Влада Семёнова, Максим Покалёв, Ания Хисмәтова, Ратмир Ахияров, Ринат Хәсәншин һ. б. тулыландырды.

Цензура

Казан шәһәрендә 1800 елда беренче татар типографиясе ачылгач та, анда нәшер итәргә әзерләнгән китаплар кырыс цензура аша үтәргә тиеш булган. Галим Ә. Кәримуллин язуынча, типографиядә иң беренче чыккан әлифба һәм Һәфтияк китапларын бастыру өчен Россия императоры Павел I нең үзеннән рөхсәт алынган. Сенатның махсус фәрманы нигезендә Казанда басылачак татар китаплары өстеннән цензорлык эше 1802 елдан башлап Казан гимназиясе идарәсенә йөкләнгән. Гимназия бу эшне Оренбург мөфтиенә кушкан, мөфтинең вәкиле итеп Казан шәһәренең Иске бистә имамы Мөхәммәт бине Габдераззак билгеләнгән. Ләкин, эшендә кимчелекләр табылу сәбәпле, ул 1803 елда үк цензорлык вазифасыннан читләштерелгән. Аның урынына дөньяви цензор итеп Ибраһим Хәлфин билгеләнгән. Ягъни татар китабы өчен ике цензор – И. Хәлфин һәм мөфти җаваплы булганнар.

1812 елда университет каршында Цензура комитеты оешкач, һәр кулъязма әлеге комитет аша узган, шуның өстенә попечитель рөхсәте дә кирәк булган. Цензор вазифасын университет галимнәре И. Хәлфин, Х. Френ, К. Фукс башкарганнар. 1827 елда комитет ябылгач, Көнчыгыш телләрендә чыгачак китапларга аерым цензор итеп профессор А. Казимбәк билгеләнгән.

Ә 1840 елларда татар китабын бастыру өчен Казан хәрби губернаторыннан, хәтта эчке эшләр министрыннан рөхсәт визасы таләп ителгән. Татар китаплары цензорлары булып университетның Шәрык телләре галимнәре эшләгәннәр. 1860 еллар уртасына хәтле алар Мәгариф министрлыгына буйсынганнар.

Патша хөкүмәтенең христианлаштыру сәясәте белән бәйле рәвештә православие миссионерларының мөселман һәм татар китапларын бастыруга каршы шикаятьләр язуы сәбәпле, Казанда Коръән һәм башка мөселман китапларын бастыруны тыю турында Россия Эчке эшләр министрлыгы әмере (1845) игълан ителгән. Шуңа карамастан Казан университеты типографиясе татар һәм мөселман китапларын бастыруны дәвам иткән. Тыю турындагы әмер бигрәк тә шәхси типографияләр эшчәнлегенә кыенлык китергән.

Татар китапларын басуны тыю татар наширләре һәм матбагачылары арасында гына түгел, университетның алдынгы карашлы галимнәре арасында да ризасызлык тудырган. Татар китабын яклап чыгучылар сафында университет ректоры Н. И. Лобачевский да булган. Ул үзенең Петербургка юллаган хатында типографиядә Коръән һәм *башка дини әсәрләр генә түгел, татар һәм төрек* телләрендә әдәби әсәрләрнең дә еш басылуы, алар белән Европа ориенталистларын да тәэмин итеп тору; шуның өстенә Коръән һәм бүтән Шәрык китапларын бастырудан университет типографиясенең дә даими керем алуы, матбаганың шуннан башка яши алмавы турында хәбәр иткән.

Казанда татар һәм мөселман дини китапларын бастыруның илдәге эчке һәм тышкы сәясәттә тоткан роле аныкланган, тыю турындагы әмер 1849 елда гамәлдән чыгарылган. *Әмма шул* ук вакытта яңа киртәләр корылган: Казан цензоры шикле тоелган кулъязмаларны Петербургка – цензураның баш идарәсенә җибәрергә тиеш булган, ә мәгариф министры басылырга тиешле китапларның кулъязмаларын цензура өчен Синодка җибәрүне дә таләп иткән. Хәтта Казандагы Шәрык китаплары цензоры А. Казимбәк тә, үзенең төрки-татар теле грамматикасына багышланган хезмәтен бастырганчы, мәгариф министрыннан һәм Петербург цензорыннан рөхсәт алырга тиеш булган.

1850 елларда цензорлык эшләрен Й. Готвальд, аннан соң Н. Катанов, Н. Ильминский, Ш. Әхмәрев башкарган.

Патша хөкүмәтенең сәясәте нәтиҗәсендә татар китапларын бастыру монополиясе рус типографияләренә бирелгәч, аларны нәшер итү бәясе бик югары күтәрелгән. Шул сәбәпле китаплар чыгаруда тоткарлык барлыкка килгән. Мәсәлән, 1856–1861 елларда цензура рөхсәт биргән китапларның да яртысы басылмыйча калган. 1860 елларда татар китабын эзәрлекләү тагын да көчәйгән. Ә 1874 елда татар китаплары цензурасы Петербургка күчерелгәч, хәлләр бөтенләй кыенлашкан.

Цензура патша хакимлеген йомшак кына тәнкыйтьләгән китапларны да чыгармаска тырышкан. Мәсәлән, 1879 елда Казан университеты типографиясендә чыккан «Мәкәрҗә бәете», тиражының бер өлеше сатуга чыккач, кибетләрдән җыеп алынган, ә матбагада калган өлеше яндырылган. Бу китапта хакимият әһелләре арасындагы ришвәтчелек һәм бюрократлык ачы тәнкыйтьләнгән була. Аны бастыруга рөхсәт иткән цензор Сарруфны эшеннән чыгаралар.

1880 еллардан алып 1905 елга кадәр Петербург цензурасында хезмәт иткән В. Д. Смирнов татар китапларының иң реакцион цензоры буларак таныльган. Ул эшли башлаган еллардан алып татар авторлары цензурага биргән кулъязмаларның шактые, бигрәк тә әдәби әсәрләр басылмаган. Кайчакта авторлар цензор тарафыннан бөтенләй сызып-бозып бетерелгән әсәрләрен бастыруның мәгънәсен күрмичә, китап бөтенләй чыкмый калган.

Патша цензурасының дөньяви әсәрләрне бастыруны тыюы татарлар арасында Төркиядә чыккан китапларның күбрәк таралуына китергән. (XIX гасырда Идел буена Көнчыгыш илләреннән бер елга уртача 5–6 мең данә китап кайтарылган.) Ул чорда Төркиядә Европа телләреннән тәрҗемә ителгән фәнни хезмәтләр һәм әдәби әсәрләр шактый күп нәшер ителгән. Төрек теленда чыккан китаплар аша татар укучылары Европа әдәбияты, мәдәнияте һәм фәне белән танышкан. Кайбер татар авторлары төрекчә китапларны татарчага тәрҗемә итеп, бераз үзгәртеп бастырырга теләсәләр дә, цензорлар рөхсәт бирмәгән. Мәсәлән, французчадан төрек теленә, аннан татарчага тәрҗемә ителгән география китабын цензор В. Смирнов, француз терминологиясе күп кулланылуын һәм Россиягә караганда Төркия турында күбрәк язылган дип гаепләп, бастырудан тыйган. Ул татарларда патша хөкүмәтенә карата тәнкыйди фикер тудырырдай рус һәм Европа әдипләре әсәрләренең зарарлы тәэсиреннән «саклауга» күп көч куйган. Н. В. Гогольнең татарчага тәрҗемә ителгән «Ревизор» китабын, А. С. Пушкин һәм Л. Н. Толстой әсәрләрен бастыруга да зур каршылык күрсәткән, шулай ук рус теленнән тәрҗемә ителгән медицина китапларын бастыруны да тыеп килгән.

Россиядәге 1905 елгы сәяси һәм иҗтимагый үзгәрешләр уңаеннан татар мөселман матбугатына карата үзенең фикерен белдереп, цензор В. Смирнов татарларны роман, повесть, әкиятләр һәм башка әсәрләр тарату юлы белән бөтен мөселманнарны берләштерергә омтылуда гаепләп, цензураны бетерергә ярамавы турында кисәткән.

1905 елда татар китаплары цензурасы Казанга күчерелгән, һәм цензор итеп төрки телләр галиме, этнограф Н. Ф. Катанов билгеләнгән.

Россиядәге 1905 елгы революция нәтиҗәсендә цензура вакытлыча бетеп тора. Дин һәм җәмәгать эшлеклесе Габдерәшит Ибраһимовның Петербургта басылган «Бең өч йөз сәнәлек бер нәзирә» (1905) китабы цензура бетерелгәч чыккан беренче татар басмасы булган.

Империализмның ышанычлы цензура коралы 1907 елның башыннан янәдән эшкә керешә – революцион һәм демократик матбугатка каршы һөҗүм ача. Бу чорда, Казан цензурасыннан тыш, татар матбугатын Петербургта да күзәтәләр, икеләтә цензурадан узган басмаларны миссионерлар һәм Эчке эшләр министрлыгының махсус жандарм комитеты тикшерә. Өстәвенә консерватив дин әһелләре шикаятьләр язып тора.

XX гасыр башында патша цензурасы татар китапларында революцион чаткылар һәм панисламизм пропагандасын үткәрмәү өчен зур тырышлык куйган. Нәтиҗәдә басылып чыккан китапларның тиражлары да типографияләрдән һәм кибетләрдән конфискацияләнгән, матбага хуҗалары һәм авторлар хөкемгә тартылган. Цензура һәм хөкүмәт эзәрлекләве нәтиҗәсендә типография хуҗалары зур штрафлар түләргә мәҗбүр ителгән, ә кайбер матбагалар хөкүмәт тарафыннан ябылган. Бигрәк тә Казан шәһәрендәге Шәрәф матбагасының язмышы катлаулы шаукымга эләккән. Мәсәлән, 1907 елда бу басмаханәдә чыккан Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Зариф Бәшири, Нәҗип Думави кебек шагыйрьләрнең җыентыклары, русчадан татарчага тәрҗемәдә басылган сәяси китапчыклар цензура эзәрлекләвенә дучар ителгән. Гомумән, Шәрәфләр типографиясендә басылган барлык 106 исемдәге китапның 20 гә якыны патша цензурасы тарафыннан эзәрлекләүгә яки конфискациягә эләккән. Патша һәм хакимияттән көлү чалымнары «табылган» казах телендәге китап бастыру бу матбаганың хөкүмәт тарафыннан ябылуына сәбәп булган.

1907 елда Петербургтагы «Өлфәт» матбагасында Габдерәшит Ибраһимов төрек галиме Гариф бәкнең «Бең бер хәдис шәриф шәрхе» китабын татарчага тәрҗемә итеп һәм үз аңлатмаларын да өстәп бастырып чыгарган. Китапның

үзендә цензор рөхсәте бирелү турында искәртелмәгән. Бу – Ибраһимовның иң күп гауга чыгарган хезмәтләреннән берсе. Ул анда хөр фикерләр үткәргән, патша хөкүмәтенә һәм кадимчеләргә каршы көчле тәнкыйть уты ачкан. Ләкин бу китапка, шулай ук Г. Ибраһимовның «Чубан йылдызы» («Чулпан йолдызы») һәм бүтән китапларына да арест салынып, типография ябылган, «Өлфәт» газетасы чыгудан туктатылган. Бу авторның китапларын уку тыелган. 1911 елда «Бең бер хәдис шәриф шәрхе» китабы панисламизмга каршы көрәш документларында да телгә алынган һәм Иж-Бубый мәдрәсәсен туздырганда Ибраһимов китабының китапханәдә табылуы җинаять гаепләвенә бер маддә буларак өстәлгән.

Цензура кайчагында «шикле» китапларга соңарып кына игътибар иткән. Мәсәлән, шагыйрь Мәҗит Гафуриның Шәрәф матбагасында 1908 елда басылган «Яшь гомерем» җыентыгына 1914 елда арест салынган. Ләкин бу вакытта инде китапның тиражы сатылып беткән була.

Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, цензура тагын да кырысланган. Сугыш белән бәйле рәвештә татар матбугатын хәрби цензура да күзәткән. Шул чорда, мәсәлән, «Вакыт» матбагасында 1913 елда басылган «Әхмәд Мидхәт әфәнде» һәм 1914 елда чыккан «Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр» китаплары өчен тарихчы Р. Фәхретдин 1915 елда хөкемгә тартылган.

Татар авторлары пьесаларының патша цензурасы тыю сәбәпле басылмыйча калган 140 данә кулъязмасы Россия Федерациясенең Петербургтагы Дәүләт театр китапханәсендә саклана. Алар арасында классик әдипләребез Г. Камал, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, К. Тинчурин пьесалары да бар.

XX гасыр башында басылып чыккан татар китапларының саны алдарак күрсәтелгән иде. Әмма ул санны да абсолют төгәл дип әйтеп булмый. Чөнки цензура бетеп торган 1905–1906 елларда чыккан һәм рәсми теркәлмәгән китаплар да шактый. 1907 ел башыннан цензура яңартылганнан соң да, кайбер татар китаплары тикшерү үткәрелми генә чыгарылган.

Патша чоры цензурасын Ә. Кәримуллин «татар мәдәнияте өстендәге рухи жандармерия» дип бәяләгән.

Татар китабының гомуми саны, аның репертуары һәм иҗади куәте, эчтәлекләренең дәрәҗәсе турында фикер йөрткәндә һәм бәя биргәндә, басылып чыккан китапларның рәхимсез цензура тураган әсәрләр булганлыгы һәрвакыт истә тотылырга тиеш. Шуның белән беррәттән татар авторларының, цензура рөхсәт бирмәве сәбәпле, бөтенләй дөньяга чыкмый калган әсәр кулъязмаларының күп булуын да онытырга ярамый.

Россиядә 1917 елгы революциядән соң матбугат һәм нәшрият цензурасы яңача – советча төсмер ала. 1918 елда Казан губернасында оештырылган Полиграфсекция (соңрак Полиграфия бүлеге, Главлитның Татарстан бүлеге), матбагаларның эшен оештыру һәм күзәтү-тикшерү белән беррәттән, аларда нәшер ителә торган басмаларның идеологик юнәлешен контрольгә ала. Ягъни коммунистик тәгълиматка каршы килгән яисә кулай булмаган китап-брошюралар чыгару тыела. Моны күзәтеп бару максатында һәр басманың мәҗбүри нөсхәләрен тикшерергә тапшыру таләп ителгән.

Совет цензурасы елдан-ел кырысланган. Бары тик 1950–1960 еллардагы «Хрущёв җепшеклеге» дәверендә генә татар китабын бастыруда бераз иркенлек күзәтелә. Совет чорында исемнәре тыелган һәм репрессияләнгән әдипләрнең әсәрләре шул елларда басылып чыгып, рухи-мәдәни тормышка саф дулкын булып тарала. Әмма бу иркенлек 1960 еллар уртасына кадәр генә дәвам итә. Аннан соң Коммунистлар партиясе китап-нәшрият эшчәнлеген тагын корыч кысаларга ала: китапларда Октябрь революциясе һәм аның юлбашчыларына, эшче-крестьяннар партиясенә дан җырлау, совет агитациясен һәм пропагандасын үткәрү кебек максатлар куела. Шушы «тугры юл»дан аз гына тайпылу да кимчелек дип саналып, китапларның чыгуын кичектерә яки бөтенләй тыя.

Илдәге иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр нәтиҗәсендә 1990 елларда коммунистик цензура юкка чыкты. Бу исә, бер яктан, каләм әһелләренә күптән көтелгән рухи иркенлек һәм зур иҗади мөмкинлекләр ачты. Әмма китап дөньясы тәнкыйтьне танымаучы һәм үзтәнкыйтьне белмәүче графоманнарның элементар редакцияләү үтмәгән зәвыксыз чүпләре белән тапланды.

Миссионерлык китаплары

Европада төрки телләрне өйрәнү миссионерлык максатларында башланган. XIV гасыр башында үк Рим миссионерлары Алтын Урдада яшәгән төрки-команнарны өйрәнүгә керешкәннәр. Нәкъ шул заманда кыпчак (коман) телендә язылган «Кодекс куманикус» китабы хәзерге вакытта Италиянең Венеция шәһәре китапханәсендә саклана. Ул латин-фарсы-коман һәм коман-немец сүзлекләрен эченә алган ике дәфтәрдән тора. Анда шулай ук кыпчак грамматикасыннан мәгълүматлар, кыпчак теленә тәржемә ителгән Тәүрат хикәятләре, табышмаклар бирелгән. Аннан соңгы гасырларда католик миссионерларының эше тагын да киңәйгән. XVII–XVIII гасырларда Европада кыпчак-татар телендә нәшер ителгән китаплар «Төрки телләр институты» дигән гриф астында басылган. Ул чорларда Европадагы күп илләр «Изге Рим империясе» составына кергән. Ватикан мәҗбүр итү һәм пропаганда ысуллары белән Европада һәм аннан

читтә дә католик динен тараткан. «Изге империя»нең бөтен илләрендә дә диярлек «ориенталь телләр» институтлары эшләгән һәм аларның бүлекчәләре рәвешендә төрки телләр институтлары булган. Институтларда гарәп, фарсы, төрек, татар, әрмән, грузин һәм башка телләрдәге грамматика китаплары һәм сүзлекләр чыгарылган. Дөресрәге, алар ике телдә, мәсәлән, кыпчак-татар һәм латинча яисә кыпчак-татар һәм итальянча басылганнар. Андыйлардан, мисал итеп, Шәрыкне өйрәнүче Джованни Молиноның 1641 елда Римда чыгарган «Итальян-төрки сүзлеге»н, Франциско-Марио Магджионың 1643 елда шулай ук Римда басылган «Кыпчак грамматикасы»н, Бернардо да Паригиның 1665 елда Римда дөнья күргән «Итальян-кыпчак сүзлеге»н (исеме «Сүз китабы» дип татарча да бирелгән), Франческо Менинскийның 1660 елда Венада нәшер ителгән «Төрки телләрнең гарәп һәм фарсы телләре белән чагыштырма грамматикасы»н атарга мөмкин. Лейпциг университетында укыткан профессор Иероним Мегизерның Лейпцигта *1612 елда, ягъни тагын да әүвәлрәк* басылган «Төрки тел нигезләре» хезмәте, төрки тел грамматикасыннан, төркичә-латинча, латинча-төркичә сүзлектән торса да, югарыда аталган китаплар рәтендә.

Ул заманда Европада гарәп хәрефләре белән кыпчак-татар телләрендәге китаплар бастыруның төп максаты католик миссионерлары өчен кулланма әзерләүдән гыйбарәт булган. Бер яктан, саф лингвистик яссылыкта бәяләгәндә, элекке чор төрки-татар теле тарихын өйрәнү өчен андый китаплар кыйммәтле чыганак булсалар, *икенче җәһәттән* караганда, алар татар милли басмасы дип исәпләнә алмыйлар. Чөнки ул китаплар татарларны аңлы-белемле, мәгърифәтле итү өчен чыгарылмаган, татар җирлегендә басылмаган, татарлар арасында таралмаган һәм кулланылмаган. Татар мәгърифәте һәм мәдәниятенә хезмәт итмәгән. Асыл максаты – Идел-Урал буйларындагы мөселман динен тотучы төрки-татарларны ата-бабаларыннан килгән рухи яшәешләреннән ваз кичтереп, чукындырып, христиан диненә кертү өчен хәзерләнгән китаплар һичничек татар халкы китабы була алмый.

«Татар китабы» дигән төшенчә киң тарихи мәгънәгә ия. Гомерен һәм гыйльми көч-куәтен татар китабы тарихын өйрәнүгә багышлаган абруйлы белгеч, академик, филология фәннәре докторы Әбрар Кәримуллинның милли китап турындагы сүзләренә мөрәҗәгать итик. Ул болай язган иде: «Милли китап билгеләмәсе турында сүз йөрткәндә, теге яки бу басманы кайсы халыкның милли китабы икәнен билгеләгәндә, китапның кайда, кем, нинди халык тарафыннан басылуын, әсәрнең авторы кайсы милләт кешесе булуын ачыклау белән бергә китапның кайсы халыкка яки халыкларга хезмәт итүен, икенче төрле әйткәндә, китапның функциональ ролен, ул халыкның культура, мәгарифендә тоткан урынын да бик ачык итеп күзалларга кирәк».

Католик һәм лютеран чиркәүләре тарафыннан кыпчак-татар һәм башка телләрдәге дини китаплар XVIII һәм XIX гасырларда да чыгарылган. 1802 елдан башлап Төньяк Кавказның Биштау шәһәре янындагы Каррас авылында һәм Әстерхан шәһәрендә шотланд миссионерлары урнашып, Библия җәмгыятьләре оештырганнар, җирле халыкны үз диннәренә өндәргә, үзләре төрки телләрне өйрәнергә керешкәннәр. (Соңрак Казан университеты профессоры булган Александр Казимбәк – шотланд миссионерларына татар һәм фарсы телләрен өйрәткән һәм үзе дә алар йогынтысы белән христиан диненең протестантлык тармагын кабул иткән мәгълүм затларның берсе.)

Европа миссионерлары, Англиядән типография һәм гарәп шрифтларын китертеп, татар, гарәп һәм фарсы телләренә тәрҗемә ителгән христиан дине китапларын (Инҗил, Библия һәм бүтән чиркәү китапларын) гарәп шрифтында бастыра башлаганнар. Аларны Идел-Урал буйларында, Кырымда һәм Көнбатыш Себердә яшәгән татарлар арасында күп санда түләүсез таратканнар. Типографиянең беренче китабы – төрки-татар телендәге христиан катехизисы («Бер дуслык кәләмә мөселманә») 1806 елда Карраста басылган. Андагы шотланд миссионерларының бер өлеше Әстерханга күчеп, тагын бер басмаханә – Митчел типографиясен оештырганнар. Биредә гарәп хәрефләре белән беренче «Инҗиле мөкаддәс» 1810 елда нәшер ителгән. Бу типографиядә татар телендә берничә дистә китап чыкканлыгы мәгълүм.

1821 елда Кавказга Европадан «Базель Инҗил җәмгыяте» миссионерлары да килеп урнашканнар һәм төрки-татар, шулай ук башка телләрдә китап бастыруга керешкәннәр.

Католик миссионерлар, киң эшчәнлек җәелдерсәләр дә, зур уңышка ирешә алмаганнар. Алар бастырган китаплар барлыгы 23 исемдә булып, бөтенесе дә түләүсез өләшенгән. 1836–1837 елларда Россия императорының фәрманы нигезендә католик миссионерлары Кавказдан һәм Әстерханнан китәргә мәҗбүр булганнар.

Илдә чиркәү эшләре белән идарә итүче югары дәүләт органы Синод һәм миссионерлар Россия империясендә яшәгән рус булмаган халыклар арасында христиан динен тарату өчен матбугатны ышанычлы корал һәм үтемле чараларның берсе буларак кулланганнар. XVIII гасыр башында һәм уртасында ук православие дине китапларын татарчага тәрҗемә итеп бастыру омтылышлары ясалган. Әлеге гамәлләр кәрәшен татарларының һәм бүтән халыкларның күпләп христиан диненнән ваз кичүләре чорында – XIX гасырның беренче дистә елларында башлан-

ган. Рус булмаган, христиан динендәге халыклар арасында православиене саклап калу өчен каралган төрле чараларның берсе буларак, Синод һәм патша хөкүмәте дини эчтәлектәге китапларны христиан диненнән баш тартучыларның сөйләм тел-ләрендә бастырырга ниятләгән. Миссионерларның төп максаты православие нигезендә руслаштыру булган.

Идел һәм Урал буйларында, Себердә һәм Кавказда яшәгән рус булмаган халыкларны христианлаштыру максаты белән, миссионерлык хәрәкәтенең үзәге буларак, 1797 елда Казан руханилар академиясе ачылган. Чиркәү догалары һәм катехизисның татарчага Казан руханилар академиясендә тәрҗемә ителгән китабы кириллица белән 1805 елда Мәскәүдә Синод типографиясендә басылган. 1830–1850 елларда Казанда православие дине китапларын татарчага тәрҗемә итеп бастырганнар. Аларны тәрҗемә итүчеләр: Казан университетының төрек-татар теле укытучысы А. Казимбәк, Казан руханилар академиясенең «Мөселманлыкка каршы» бүлегендә белем алган Н. Ильминский, рухани Г. Саблуков һ. б. булган. XIX гасыр уртасында тәрҗемә комиссиясе Петербургка күчерелгән, һәм христиан китаплары алга таба шунда басылган.

1860 елларда Н. Ильминский татар телендә православие китапларын бастыруга зур өлеш керткән, 1863 елда беренче керәшен-татар мәктәбен оештырган. 1862 елдан татарча басылган миссионерлык китаплары фәкать рус графикасы белән генә чыккан. 1867 елда Казанда «Братство Святого Гурия» оешмасы ачылгач, керәшен татарлары өчен китаплар бастыру шуңа йөкләнгән. Ә 1872 елда Казанда миссионерлар өчен махсус Укытучылар семинариясе ачылган, һәм аның директоры итеп Н. Ильминский билгеләнгән. Җирле халыкларга карата колониаль изү сәясәте алып барган патша хөкүмәте нинди генә чаралар күрсә дә, 1860–1870 елларда 50 меңнән артык керәшен татары, үзләренә көчләп тагылган православиедән ваз кичеп, мөселманлыкка кайтканнар.

Әбрар Кәримуллин ачыклавынча, 1862–1879 еллар арасында татар телендәге христиан китаплары 307 исемдә булып, аларның гомуми тиражы 80 462 данәне тәшкил иткән. Бу китаплар арасында тарих, география, арифметика һәм башка төр китаплар бер дә булмаган.

Аннан соңгы елларда да миссионерлык китапларын бастыру дәвам иткән. Ләкин 1905 елдан соң Н. Ильминский җитәкчелегендәге миссионерлар патша хөкүмәтенә һәм монархиягә дан җырлап, рус булмаган халыклар арасында дөньяви белемнәрнең таралуына актив каршы торган. 1907–1915 елларда керәшен татарлары өчен барлыгы 10 исемдәге китап бастырылган.

XIX гасырның башыннан алып XX гасыр башына кадәр чит ил һәм рус миссионерлары тарафыннан төрле телләрдә барлыгы 448 китап басылып, шулардан 347 басма татар телендә булган, аларның гомуми тиражы якынча 830 мең данәне тәшкил иткән.

1917 елдан соң нәшриятлар эшчәнлеге

Татарстанда. Россиядә Совет хакимияте урнашкач, Халык Комиссарлары Советы 1917 елның 27 октябрендә кабул иткән «Матбугат турындагы Декрет» нигезендә полиграфия һәм китап бастыру эшләре дәүләт карамагына алынып, нәшрият эшчәнлеге зур үзгәрешләр кичерә. Электән эшләп килгән типографияләр һәм нәшриятлар совет оешмалары контроленә алынып, 1918 елда хосусый татар матбагаларының күпчелеге аларга беркетелә. 1917 елдан соң Казанда 20 хосусый нәшрият кооперативы эшләгән. Шулардан «Игенче», «Яңалиф» (яңа әлиф), «Гәжур» (гәзит-журнал) нәшриятлары татар китаплары бастыру буенча махсуслашкан булган.

«Игенче» нәшрияты. Әлеге нәшрият 1921 елның 2 июнендә Татарстан Җир эшләре халык комиссариаты каршында эшли башлый. Бу вакытта, авыл хуҗалыгындагы революцион үзгәрешләр сәбәпле, крестьяннар өчен бик күп китаплар бастыру ихтыяҗы туган. Бу нәшриятка үз эшен Идел буендагы ачлык афәте һәм Гражданнар сугышыннан соңгы авыр икътисади шартларда башлап җибәрергә һәм җайга салырга туры килгән. Бирелә басылган китаплар тиражының бер өлеше бушка таратылган. «Игенче» нәшрияты тарафыннан 1921–1930 елларда барлыгы 404 исемдәге китап чыгарылган һәм аларның гомуми тиражы якынча 1,5 миллион данәгә якын булган. Бу нәшриятта чыккан китапларның аңлаешлы телдә һәм рәсемнәр белән басылуы крестьяннар өчен уңайлы булган. «Игенче» нәшрияты чыгарган, авыл хуҗалыгының бөтен тармакларына да караган китап-брошюраларның күбесе рус теленнән тәрҗемә ителгән. Махсус әдәбиятны татарчалаштыру 1917 елга кадәр үк эшләгән белгечләр, татар язучылары һәм журналистлары тарафыннан башкарылган.

Бу нәшрият тарафыннан бастырылган китаплар татарлар яшәгән губерналарга, Башкортстанга, Казахстан, Урта Азия һәм Азәрбайҗанга һәм Себергә җибәрелгән. «Игенче» бастырган китаплар Башкортстанда аеруча күп таралган. Ә. Кәримуллин билгеләвенчә, бу нәшрият күрше ике республика өчен хезмәт иткән. Шул сәбәпле 1930 елларга кадәр Башкортстанда авыл хуҗалыгы буенча китаплар басылмаган диярлек. 1929 елның 13 ноябрь карары нигезендә «Игенче» нәшрияты Татгосиздат белән берләштерелгән.

«Гәжур» нәшрияты. 1925 елның көзендә оештырылган. Аның карамагына «Шәрык» типографиясе тапшырылган. Төп эше газета һәм журналлар нәшер итү булса да, бу нәшрият китаплар да бастырган. 1925–1927 елларда «Гәжур» нәшрияты тарафыннан 45 исемдәге китап 274 500 данә го-

муми тираж белән чыккан. Алар арасында әдәби әсәрләр, балалар өчен китаплар, матбугат эшчәнлегенә багышланган хезмәтләр һәм бүтән төр басмалар бар.

«Яңалиф» нәшрияты. Әлеге нәшрият эшчәнлеге гарәп алфавиты нигезендәге татар язуын латин алфавитына күчерү тарихы белән бәйле. 1926 елның февраль аенда Бакуда узган Беренче бөтендөнья тюркология съездында Советлар Союзындагы төрки халыкларның язуларын латин алфавитына күчерү турындагы мәсьәлә каралган. Шушы съезд карарлары нигезендә төрле республика һәм өлкәләрдә «Яңалиф» җәмгыятьләре оештырылган.

Казан шәһәрендә 1926 елның октябрендә нигезләнгән «Яңалиф» җәмгыяте, латин язуына күчүне пропагандалау йөзеннән, шул ук елда нәшрият эшчәнлеге белән дә шөгыльләнә башлый.

1926–1932 еллар арасында «Яңалиф» нәшрияты тарафыннан барлыгы 198 исемдәге татар китабы 1 миллионнан артык тираж белән басылып чыккан. 1928–1929 елларда аеруча күп китап нәшер ителгән. Бу нәшрият чыгарган китапларның күбесе латин язуындагы әлифбалар һәм орфография китаплары, яңа алфавит нигезендәге әдәби әсәрләр һәм уку китаплары булган. Рус әдипләренең татарчага тәрҗемә ителгән әсәрләре дә шактый басылган. Китапларның тиражлары зур – уртача 5 мең данә булган. Латин язуы әлифбалары хәтта 100 әр мең данә тираж белән басылган.

1930 елның башында татар телендәге бөтен китаплар да яңа алфавит – латин язуы нигезендә бастырылган. Шул елның көзендә «Яңалиф» нәшрияты тулаем диярлек Татиздатка кушылган.

Гомумән, 1917–1932 елларда Казанда басылган татар китапларының саны 2395 исемдә булып, аларның тиражы 10 миллион тирәсенә җиткән. Ә 1918–1929 еллар арасында Советлар Союзында 4088 исемдәге татар китаплары басылып чыккан һәм аларның гомуми тиражы (билгеле булганы) 15,5 миллион данәне тәшкил иткән.

1917–1932 елларда Татарстандагы өяз һәм кантон шәһәрләреннән Алабуга, Бөгелмә, Мамадыш, Минзәлә, Чаллы, Чистайдагы типографияләрдә дә татарча китаплар нәшер ителгән. Аларның күпчелеге партия һәм совет оешмалары тарафыннан чыгарылган иҗтимагый-сәяси брошюралар булган.

Татарстан китап нәшрияты. РКП(б)ның Казан губерна комитеты карары белән 1919 елның 22 июлендә РСФСР Дәүләт нәшриятының (Госиздатның) Казан бүлеге (Казгосиздат) оештырыла. Хәзерге Татарстан китап нәшрияты үз тарихын шушы вакыттан исәпли.

Дәүләт нәшриятының Казан бүлеге 1920 елның 3 ноябрендә Татгосиздат (Татарстан дәүләт нәшрияты) итеп үзгәртелә. Ул, оешкан елларыннан ук, татар телендә матур әдәбият, фәнни-популяр һәм сәяси-иҗтимагый эчтәлектәге китаплар чыгаручы иң эре нәшриятка әверелә.

Типографияләр эшен оештыру, планлаштыру һәм контрольдә тоту 1923 елга кадәр Полиграфсекция, Полиграфия бүлеге, ТАССР Полиграфия сәнәгате баш идарәсе, «Казпечать», «Татпечать» оешмалары карамагында булган. 1923 елның апрель аенда Татарстандагы нәшрият һәм полиграфия эшләре өчен җаваплы идарә сыйфатында ТАССР нәшрият һәм матбугат комбинаты оештырыла.

1925 елның июлендә бу комбинат Татгиз итеп үзгәртелә. 1927 елда Татгиз һәм «Гәҗур» бергә кушылып, Татарстан АССРның Башкарма Комитеты карамагындагы Татиздат буларак оештырыла. Шул ук елда Татполиграфтрест оешмасы Татполиграф дип үзгәртелә. Бу оешмада Татарстан һәм башка төрки республикалар һәм өлкәләр (башкорт, үзбәк, каракалпак, казах, кыргыз һ. б.) матбугаты өчен башта гарәп, аннары латин һәм 1930 еллар ахырыннан рус графикасы нигезендәге шрифтлар хәзерләнә. Гомумән, Казандагы полиграфия оешмалары 1920 еллар уртасына кадәр СССРдагы Шәрык типографияләре һәм бөтен мөселман халыклары матбугаты өчен гарәп-төрки шрифтлары әзерләнгән бердәнбер үзәк булган. Шулай ук Урта Азия һәм Казахстан заказлары буенча үзбәк, фарсы, таҗик, казах, кыргыз, каракалпак һәм бүтән Көнчыгыш телләрендәге китаплар да бастырылган. Совет чорындагы татар китапчылыгы, патша заманындагы милли китап кебек үк, башка төрки халыкларга да хезмәт иткән.

Барлык шәхси һәм кооператив нәшриятлар һәм типографияләр (югары уку йортларының фәнни әдәбият кына чыгаручы нәшриятларыннан тыш) ябылып беткәннән соң, 1931 елда Татгосиздат Татарстанда татар телендә китаплар нәшер итүче бердәнбер нәшрият булып кала. СССР Үзәк нәшриятының Татарстан бүлеге 1932 елда бетерелгәч, 1991 елга кадәр Советлар Союзындагы бердәнбер шундый үзәк вазифасын үти.

Бөек Ватан сугышының гаять авыр вакытларында фронттагы һәм тылдагы совет кешеләренең иң ныклы рухи таянычы китап булган. Хәрби, сәяси эчтәлектәге китаплар һәм матур әдәбият әсәрләре гражданнарның какшамас бердәмлеген ныгытып, халыкны изге көрәшкә туплаган һәм аларда илбасарларны җиңүгә ышаныч тудырган.

Бөек Ватан сугышы башлангач, авторлар, полиграфчылар һәм иҗади коллективлар фронтка мобилизацияләнү сәбәпле, китап бастыру эше зур кыенлыклар кичерә. Татарстан дәүләт нәшриятындагы тәҗрибәле белгечләрнең күбесе

яуга китә. Аларның 16 сы батырларча сугышып һәлак була. Алар: нәшрият җитәкчесе Ш. Арсланов, хезмәткәрләр Н. Баян, К. Басыйров, А. Бендецкий, Р. Ильяс, Ф. Кәрим, Т. Әхмәдиев, М. Фәтхуллин, Ә. Гыймадов, Х. Гаффаров, К. Шәйхетдинов, Н. Карпов, Г. Мусин, Ә. Төхфәтуллин, Л. Әлмәшев, М. Вәлиева.

Авыр сугыш чоры шартларында нәшрият һәм полиграфия хезмәткәрләре армый-талмый эшлиләр. Ул елларда Казанга эвакуацияләнгән үзәк матбугат һәм нәшриятларның 24 төрле оешмасы тарихи Матбугат йортында урнашкан. Шул сәбәпле эшләрне башкару өчен мәйдан җитешмәгән. Эшче куллар, кәгазь һәм бүтән кирәкле материаллар кытлыгы, эш урыннарының салкын булуы да күп кыенлыклар тудыра. Тик шуларга карамастан нәшрият коллективы тыл һәм фронтны китаплар, брошюралар, плакатлар һәм башка төр басмалар белән тәэмин итеп тора.

Кырыс сугыш шартларында китаплар тематикасы кискен үзгәрә, тыныч вакыт өчен яраклы басмалар саны кими. 1940 ел белән чагыштырганда, 1943 елда басылып чыккан продукция ике тапкырга диярлек азрак була.

Китап нәшриятында ул елларда басылган китапларның күпчелеген иҗтимагый-сәяси, хәрби-фронт әдәбияты тәшкил итә. Бу сериядән барлыгы 670 китап һәм брошюра чыгарылып, аларның гомуми тиражы 10 миллионнан артып китә. Болар бөтен басмаларның 42% ы тирәсен тәшкил итә. Әлеге төр басмаларда партия һәм совет юлбашчыларының сугыш һәм Ватанны саклау турындагы хезмәтләре, Башкомандующий боерыклары һәм чыгышлары, шулай ук илнең башка җитәкчеләренең нотыклары бирелә. Фашист илбасарларының реакцион чынбарлыгын, вакытлыча оккупацияләнгән территориядә дошманнар ерткычлыгын фаш иткән басмалар татар һәм рус телләрендә нәшер ителә. Кызыл Армиянең Бөек Ватан сугышы фронтларындагы каһарманнарча көрәшенә багышланган әдәбият та шактый күләмдә басыла. Совет халкы һәм Ватан тарихында булып үткән сугышчан-героик вакыйгалар, данлыклы полководецлар турындагы популяр китаплар сериясе нәшер ителә. Шулар белән берлектә совет халкының тылдагы батырларча хезмәтен яктырткан китапларга һәм әсәрләргә зур әһәмият бирелә.

1943 елның мартында «Фронтовик татарларга татар халкыннан сәлам хат» 40 меңнән артык тираж белән татар телендә һәм 20 меңнән артык данәдә рус телендә бастырыла. Бу тарихи документның төп нөсхәсенә 1,5 миллионнан артык кеше имзаларын куйган. Әлеге китап бик күп фронтовик якташларыбыз белән бергә аяусыз фронтларны кичкән. Хатка 1 нче Украин фронты һәм 2 нче Белорус фронтындагы татар сугышчыларының җавап хатлары да 15 әр мең тираж белән ике телдә нәшер ителгән.

Бөек Ватан сугышы елларында китап нәшриятында матур әдәбият әсәрләре 220 исемдәге китап һәм брошюра рәвешендә басылган (бу санга балалар һәм яшүсмерләр китаплары керми). Аларның гомуми тиражы 1,5 миллионнан артып киткән. Әлеге әсәрләр арасында повестьлар, сәхнә әсәрләре, шигъри җыентыклар, җырлар, әкиятләр, хәрби һәм әдәби очерк жанрларына караган басмалар шактый. Гаять кыен еллар булуга карамастан, татар классик әдипләренең академик басмаларын, сайланма әсәрләрен чыгару да дәвам итә. Татар телендәге китаплар фронтка һәм госпитальләргә соратыла һәм җибәрелә.

Ватан сугышы елларында фәнни-техник әдәбият нәшер итү арта. Бу хәл югары квалификацияле фән белгечләренең Казанга эвакуацияләнеп килүе белән аңлатыла. Авыл хуҗалыгының төрле тармакларына караган китаплар да шактый басылган (барлыгы 161 исемдә, гомуми тиражы 700 меңнән артык). Мәдәният өлкәсенә караган китаплар да дөнья күргән. Шул рәвешчә китап нәшрияты авыр сугыш еллары сынауларын намус белән үтеп, фашист илбасарларын җиңүгә лаеклы өлеш кертә.

Ул елларда Мәскәү һәм Ленинградтан эвакуацияләнгән СССР Фәннәр академиясенең, СССР Оборона халык комиссариатының, Сәламәтлек саклау халык комиссариатының һәм «Советский писатель» нәшриятларының авторлар һәм хезмәт коллективлары Казанга күчеп килүе республикабыз матбугатына зур йогынты ясый һәм гамәли ярдәм күрсәтә. Әлеге үзәк нәшриятлар Казанда эшләгәндә (бигрәк тә 1941–1942 елларда), аларның 194 исемдәге китап һәм хезмәтләре дөнья күргән (гомуми тиражлары 2,5 миллионнан арткан).

Татгосиздат 1954 елдан Таткнигоиздат дип атала башлый, ә 1958 елдан хәзерге рәсми исеме белән Татарстан китап нәшрияты дип йөртелә. Ул 1963 елда 1006 (шуның 593 е татар телендә) китап бастырып чыгара. Әмма 1970 елларда – 1980 еллар башында татар телендәге басмалар саны кими.

Гомумән алганда, хәзер Татарстанда басылып чыга торган татар телендәге китапларның яртысыннан артыгы, рус телендәге китапларның өчтән бере – Татарстан китап нәшриятының хезмәт казанышы. 2008 елда 312 мең данә тираж белән 120 исемдәге (шуларның 89 ы татар телендә) китап нәшер ителгән. 2012 елда нәшриятта 209 исемдәге китап дөнья күрде (шуларның 162 се татар телендә). Аларның тиражы 615 850 данәне тәшкил итә (бу саннарга дәреслекләр, эш дәфтәрләре, методик ярдәмлекләр дә керә).

«Мәгариф» нәшрияты. 1991 елда Татарстан китап нәшриятыннан бүленеп чыга. Анда, нигездә, мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен татар телендәге дәреслекләр һәм уку-укыту ярдәмлек-

ләре, Татарстанның һәм Россия төбәкләренең татар мәктәпләре өчен дәреслекләр, рус мәктәпләре өчен татар теле һәм татар мәктәпләре өчен рус теле дәреслекләре, сүзлекләр, балалар әдәбияты әсәрләре һәм башка басмалар нәшер ителә. «Мәгариф» милли нәшриятында ел саен якынча 150 исемдәге, гомуми тиражы миллионнан артык данәне тәшкил иткән китаплар дөнья күрде. 2010 елда «Мәгариф» нәшрияты яңадан Татарстан китап нәшрияты белән берләштерелде.

1990 елларда, базар икътисады шартларында, нәшриятларны хосусыйлаштыру башлана, шәхси фирмалар оеша. Басмаларның тематикасы төрләнә, коммерциячел һәм дини әдәбият бастыру күбәя. Шул вакыттан башлап хәзергә кадәр «Раннур», «Заман», «Хәтер», «Җыен», «Рухият», «Иман», «Милли китап», «Гасыр» һ. б. нәшриятлар уңышлы гына эшләп килә.

Күрмәүчеләр өчен китаплар. Күзләре күрмәүче кешеләр өчен Брайль шрифтындагы татар китапларын нәшер итү тарихы да бик кызыклы. 1939 елда Казан университеты профессоры, атаклы тюрколог Галимҗан Шәрәф һәм хокук белгече, үзе дә күрмәүче Александр Бирилёв татар теле өчен күпертмә-төрткеле латин алфавитын төзиләр. Күрмәүче олы кешеләр өчен беренче татар әлифбасы 1934 елда басылып чыга. Яңалифтәге мондый китаплар Камил Якуб исемендәге типографиядә басыла. Татарстан Халык Комиссарлары Советы һәм Бөтенроссия сукырлар җәмгыяте чит илдән кыйммәтле махсус җиһазлар сатып алып, шушы типографиягә бушлай тапшыра. 1934 елның сентябреннән 1936 елның ахырына кадәр 15 исемдәге китап дөнья күрә. Алар күрмәүче татарлар яшәгән төрле төбәкләргә таратыла.

1939 елда, латин графикасын куллану туктатылгач, руслаштырылган брайльчә-татарча алфавит гамәлгә кертелә. Алты татар хәрефенең төрткеләр комбинацияләрен үзе дә сукыр әдип Шәриф Еникиев төзи, ул алга таба озак еллар республикада Брайль шрифты белән татарча китаплар нәшер итү эшен җитәкли. Кириллица белән барлыгы 300 дән артык мондый китап бастырыла, алар, матур әдәбияттан тыш, төрле тармакларга карый. Татарстанда гына түгел, бөтен Советлар Союзындагы бик күп сукырлар шушы китаплар ярдәмендә ныклы белем алалар һәм һөнәри вазифаларын уңышлы үтиләр. Кызганыч, 1983 елда Брайль шрифты белән татар китаплары нәшер итү эше бөтенләй диярлек туктала.

Күрмәүчеләргә мәгълүмат җиткерүнең тагын бер ысулы – «сөйли торган» китаплар яздыру. Казанда татарча мондый китапларны магнитофон тасмасына яздыру 1961 елда махсус китапханәдә башлана. Тора-бара биредә тавыш яздыру бүлеге оештырыла, хәзерге вакытка кадәр 1 мең исемнән гыйбарәт 13 мең данәдән артык язма булдырыла. Республиканың сукырлар өчен махсус китапханәсе үз эшчәнлеген елдан-ел камилләштерә бара, күрмәүчеләрнең һәм начар күрүчеләрнең матур әдәбиятка, башка төр мәгълүматларга булган ихтыяҗын кайгырта.

XXI гасыр башында сукырлар өчен әдәбият бастыруда компьютер технологияләрен куллану активлашты. «Мәгариф» милли нәшрияты, Республиканың сукырлар өчен махсус китапханәсе белән бергәләп, күрмәүчеләр өчен татар теле дәреслекләре һәм сүзлекләр, әкиятләр бастырып чыгарды.

Мәскәүдә. 1917 елның Февраль революциясеннән соң Мәскәүдә хосусый татар матбагалары ачылган. Аларның берсе «Шәрык» кооператив басмаханәсе (соңрак «Кызыл Шәрык») дип аталган. 1919 елның 30 гыйнварыннан бу типография РКП(б)ның Мөселман оешмалары Мәркәз бюросы карамагында эшли. 1917–1918 елларда «Шәрык»тә барлыгы бер дистәдән артыграк кына татар китабы чыккан.

Мәркәз мөселман комиссариаты тарафыннан 1918–1919 елларда башта Петроградта, аннан соң Мәскәүдә татар телендә революцион һәм коммунистик эчтәлектәге китап-брошюралар басылган. 1918 һәм 1919 елларда РКП(б) Үзәк Комитетының Шәрык халыклары коммунистик оешмалары Мәркәз бюросы тарафыннан да татарча китаплар нәшер ителгән. Мәскәүдә гарәп хәрефләре белән китап бастыру өчен полиграфик шартлар булмавы аркасында, Мәркәз бюро күпчелек китапларны Казандагы типографиядә нәшер иткән. 1918–1921 елларда бу оешма тарафыннан 87 исемдәге татар китабы 1,5 миллион данә гомуми тираж белән бастырылган. Эчтәлек ягыннан бу китаплар коммунистик һәм марксистик юнәлешле, Совет хакимияте һәм Коммунистлар партиясе турында булганнар.

Мәскәү шәһәрендә авырлык белән оештырылган Мәркәз Шәрык нәшрияты 1922–1924 елларда 20 исемдәге китапны 200 500 данә тираж белән нәшер иткән.

1922 елда Мәскәүдә Татар-башкорт мәркәз бюросы тарафыннан «Нәшрият» кооперативы оештырылган. Ул үзенең типографиясен булдырган. «Нәшрият» оешмасы тарафыннан 1923–1929 елларда 225 исемдәге татар китабы 1,5 миллион данәгә якын тираж белән басылып чыккан. Эчтәлек ягыннан алар күптөрле: ленинизм һәм коммунистик әдәбият, авыл хуҗалыгы, фәнни-популяр, хәрби, техник, татар классик әдәбияты, тәрҗемә әсәрләр.

«Нәшрият» оешмасының эшчәнлеге рәсми рәвештә 1928 елда тукталса да, кайбер басмалары 1929 ел башында да дөнья күргән.

Мәскәүдә 1924 елда СССР халыкларының Мәркәз нәшрияты оештырылган, һәм анда күп телләрдәге әдәбият белән беррәттән татарча китаплар да бастырылган. 1927 елга кадәр Мәркәз нәшрияты тарафыннан 203 татар китабы 1 мил-

лион 213 200 данә гомуми тираж белән басылган. Анда эчтәлек ягыннан бөтен төр тармакларга караган китаплар да чыгарылган.

Башкортстанда. Башкортстанның төрле шәһәрләрендә: Уфа, Эстәрлетамак, Бәләбәйдә 1917–1932 елларда 435 исемдәге татар китабы миллионнан артык данә гомуми тираж белән басылганлыгы мәгълүм. Соңгы елларда Уфада Зәйнәп Биишева исемендәге «Китап» нәшрияты Башкортстанның татар мәктәпләре өчен дәреслекләр чыгара башлады.

Соңгы чорда татар китаплары илебезнең татар халкы тупланып яшәүче республика һәм өлкәләрендә (аеруча Идел-Урал, Себер төбәкләрендә), эре шәһәрләрдә (Мәскәү, Санкт-Петербург) дә беркадәр нәшер ителә. Бу күренешнең милли китап сүзе таралуда, һичшиксез, файдалы өлеше бар.

Татар китабы тәрҗемәләрдә

XX гасырда татар китабының башка телләргә тәрҗемәләре дә дөнья күрде. Әлбәттә, иң беренче чиратта, татар авторларының хезмәтләре системалы рәвештә рус теленә тәрҗемә ителгән һәм Казанда гына түгел, бик еш Мәскәүдә дә чыгып торган. Совет чорында бигрәк тә Г. Тукай, М. Җәлил, Г. Кутуй, Ә. Фәйзи, З. Нури, Ж. Тәрҗеманов, Г. Бәширов әсәрләре СССР һәм чит ил халыклары телләренә тәрҗемә ителгән. Соңгы елларда Р. Мөхәммәдиев, А. Гыйләҗев, Р. Батулла китаплары Төркиядә төрек телендә, М. Хәбибуллин әсәрләре Болгариядә болгар телендә басылып чыкты. Шул рәвешчә татар китабы дөньядагы башка халыкларга да таныла, халыкара һәм милләтара багланышлар ныгуга хезмәт итә.

Китапханәләр

Татар халкы – күп гасырлар элек үк язуга, китап культурасына ия, мәдәни тарихы бай булган милләт. Бабаларыбызның Бөек Болгар, Алтын Урда, Казан, Әстерхан, Себер һәм Кырым ханлыгы кебек шанлы-шәүкәтле дәүләтләре чорларында ук дини, гыйльми, әдәби эчтәлектәге күпсанлы кулъязма китаплардан тупланган бай китапханәләре булган.

Халкыбыз тарихында беренче китапханәләр Идел буе Болгарында барлыкка килгән. Казан ханлыгында Хан сарае, мәктәп һәм мәдрәсә китапханәләре, мәчетләр каршында китап тупланмалары һәм шәхси китап җыелмалары булган. Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, әлеге китапханәләр бөтенләй диярлек юкка чыгарыла. Аларның кабат яңаруы XVIII йөздә мәдрәсәләр ачылу белән бәйле. Мөселман руханилары, татар сәүдәгәрләре шәхси китапханәләр туплаган. Ш. Мәрҗани һәм Р. Фәхретдин XVIII–XIX гасырларда яшәгән татар укымышлыларының, Бохара, Сәмәрканд, Кабул, Һиндстан, Дагстан, Истанбул һәм Каһирә тарафларында белем алып, туган илләренә үзләре белән кыйммәтле кулъязма китаплар җыеп кайтулары турында язалар. Мәгърифәтче-педагоглар Сәгыйть һәм Ибраһим Хәлфиннәрнең, татар теле галиме Мөхәммәдгали Мәхмүдовның бик бай шәхси китапханәләре булуы мәгълүм. XIX гасырда «Мәрҗания» (1870) һәм «Мөхәммәдия» (1882) мәдрәсәләре китапханәләре оеша. Алар шулай ук җәмәгать китапханәләре вазифасын да башкарган. Татар җәмәгать китапханәләре XX йөз башыннан рәсми рәвештә ачылып эшли башлый: Казанның 1865 елдан бирле эшләп килгән беренче җәмәгать китапханәсенең (хәзерге Татарстан Республикасы Милли китапханәсе) мөселман-татар филиалы буларак нигезләнгән «Көтепханәи Исламия» (1906), Алафузов фабрикасындагы татар эшчеләре китапханәсе (1906), «Шәрык клубы» китапханәсе (1908), Галимҗан Барудиның җәмәгать китапханәсе (1913), Гыйльметдин Шәрәф китапханәсе һәм уку бүлмәсе (1916) һ. б. Карл Фукс, Христиан Френ, Фёдор Эрдман, Александр Казимбәк, Николай Катанов, Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Ишмөхәммәт Динмөхәммәтев, Мөхәммәтнәҗип Түнтәри, Фатих Әмирхан, Сәет Вахиди, Юнысовлар, Апанаевлар, Аитовлар, Камаловлар, Максудилар, Акчуриннар Шәрык, шул исәптән төрки-татар кулъязмалары һәм китапларының бай тупланмаларына ия булганнар. 1910 елларда Казан хәрби гарнизоны гаскәрләрендә мөселман уку бүлмәләре оештырылганлыгы мәгълүм.

1917 елга кадәрге дәвердә татарлар күпләп яшәгән Казан, Оренбург, Мәскәү, Әстерхан, Самара, Уфа, Уральск, Сарапул, Малмыж, Чиләбе, Петропавловск, Троицк, Орск, Алабуга һ. б. шәһәрләрдә татар китапханәләре эшләп килә. Зур авылларда да җәмәгать китапханәләре оештыру эшләре башлана.

Татар китапханәләре татарлар арасында гына түгел, башка кайбер төрки халыклар арасында да татар, Көнбатыш һәм Шәрык әдәбияты үрнәкләре, дөньяви һәм фәнни белемнәр таратуда зур эш башкара.

1917 елдан соң татар җәмәгать китапханәләренең күбесе ябыла, фондларының бер өлеше юк ителә, бер өлеше яңа оешкан совет китапханәләренә таратыла. Казан губернасы халкына хезмәт күрсәтү өчен яңа массакүләм китапханәләр челтәре булдырыла һәм тора-бара киңәйтелә. Совет хакимиятенең беренче елларында 218 китапханә һәм уку заллары оештырыла, шуларның 138 е татарлар өчен тәгаенләнгән була. 1919 елда – Казанда балалар китапханәсе, 1920 елда – Татарстанның Сәламәтлек саклау халык комиссариаты китапханәсе, 1930 еллар башыннан – профсоюзлар китапханәсе, 1935 елда сукырлар өчен махсус китапханә ачыла. Бөек Ва-

тан сугышы алдыннан республикада 2251 массакүләм китапханә эшли. Сугыш елларында аларның саны кими. 1950–1960 елларда партия китапханәләре челтәре оештырыла, массакүләм китапханәләр челтәре тәртип-кә китерелә. 1960 елда Татарстан Мәдәният министрлыгы карамагында 2379 китапханә исәпләнә. 1975–1980 елларда массакүләм китапханәләр үзәкләштерелгән китапханәләр системаларына берләштерелә. 1977 елда Республика яшүсмерләр китапханәсе ачыла. 1980 елда Татарстанда – 1745 массакүләм китапханә, 2009 елда Мәдәният министрлыгы карамагында – 1580, 2012 елда – 1549, шул исәптән 1545 муниципаль китапханә һәм Татарстан Республикасы Милли китапханәсе, Республика балалар китапханәсе, Республика яшүсмерләр китапханәсе, Республиканың сукырлар өчен махсус китапханәсе эшли. Аларның фондларында барлыгы 24 миллионга якын саклау берәмлеге исәпләнә. Хәзерге вакытта Россия республикаларында һәм өлкәләрендә дә, якын һәм ерак чит илләрдә дә татар китапханәләре эшли, шулай ук фондларында татар китаплары булган, татар телле китап укучыларга хезмәт күрсәтүче китапханәләр бар.

Татарстанның иң эре һәм татар китаплары иң күп тупланган китапханәләре – Татарстан Республикасы Милли китапханәсе һәм Казан (Идел буе) федераль университетының Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсе. Татарстан Республикасының Милли китапханәсе – милли һәм республика, Россия һәм чит илләр басмаларын үзендә саклаучы, күптармаклы фәнни-тикшеренү эшчәнлеге алып баручы дәүләт оешмасы, мәдәни, библиографик һәм методик үзәк. Ул – татар мәдәниятен таныту үзәге дә, татар китабын туплау, саклау, тарату эшләре белән максатчан рәвештә шөгыльләнә торган, Россиядәге һәм чит илләрдәге татар укучыларына хезмәт күрсәтүче китапханәләр белән элемтәләр урнаштырган бердәнбер зур китапханә. Аның фондларында 3 миллион 300 мең нөсхә һәртөрле басмалар, шул исәптән татар телендәге 115 мең китап тупланган.

Хәзерге вакытта дөньяда татар китаплары түбәндәге эре китапханәләрдә саклана: Россия милли китапханәсе (Санкт-Петербург), Россия дәүләт китапханәсе (Мәскәү), Башкортстан Республикасының Әхмәтзәки Вәлиди исемендәге Милли китапханәсе (Уфа), Һельсинки университеты китапханәсе (Финляндия), Төркия парламент китапханәсе (Анкара), Истанбул университеты китапханәсе (Төркия), Нью-Йорк җәмәгать китапханәсе (АКШ).

Бөтен Советлар Союзындагы кебек үк, 1974 елда Татарстанда да массакүләм иҗтимагый оешма – Китап сөючеләр җәмгыяте төзелә. Китап пропагандалау, фәнни, сәяси һәм техник белемнәр тарату, нәшрият эшен үстерүгә булышу, иҗат берлекләре, төрле җәмгыятьләр һәм оешмалар катнашында китап күргәзмәләре, бәйге-конкурслар, әдәби юбилей кичәләре, укучылар конференцияләре үткәрү белән шөгыльләнгән әлеге җәмгыятьнең эшчәнлеге 2000 елда туктатыла.

Китап палатасы

Татарстан Республикасы Халык Комиссарлары Советы 1926 елның 21 декабрендә чыгарган карар нигезендә Татарстан АССРда, Идел буе автономияле республикалары арасында беренче булып, Китап палатасы оештырыла. Китап палатасы иң башта Галимҗан Ибраһимов җитәкчелегендәге Гыйльми тикшеренү үзәге (Академүзәк) каршындагы фәнни китапханә составына кертелгән. Китап палатасына Татарстандагы барлык типографияләр дә үзендә басылган һәр төр продукциясеннән берничә нөсхә тапшырырга тиеш булган. Моннан тыш Китап палатасы Татарстаннан читтә татар телендә чыккан басмаларны да алмашу тәртибендә яки РСФСР Үзәк Китап палатасы аша алдырган. Палатага шулай ук СССРдагы башка төрки һәм Шәрык телләрендәге әдәбиятны туплау да йөкләнгән. 1928 елда анда 37 телдәге (татар, кырым-татар, башкорт, нугай, уйгур, төрек, азәрбайҗан, үзбәк, төрекмән, карачай-балкар, каракалпак, кумык, казах, кыргыз, якут, мари, мордва, адыгей, авар, әрмән, гарәп, фарсы, таҗик, чечен, лезгин, рус, инглиз, немец, француз, еврей һ. б.) әсәрләр тупланган.

1929 елда Мулланур Вахитов исемендәге Үзәк Көнчыгыш китапханә-музеена кушылу нәтиҗәсендә, палата фондына элеккерәк елларда басмалар да өстәлгән.

Татарстан Китап палатасы оештырылуының беренче көннәреннән үк республикада чыккан китаплар турында библиография төзү эшенә дә керешкән. Бер-бер артлы библиографик басмалар һәм 1930 елдан башлап һәр квартал саен республиканың «Матбугат елъязмасы» чыга башлаган. Бу күрсәткечкә Татарстанда басылып чыккан барлык китап, газета һәм журналлар теркәлгән. Ләкин төрле оешмаларны берләштерү башлангач (1932), Китап палатасы Казан дәүләт университеты китапханәсенә кушылган, һәм елъязма чыгару эше тукталган. Палата фондындагы китаплар фәнни китапханәнең гомуми фондына күчерелгән.

1938 елда Китап палатасы яңадан мөстәкыйль оешма буларак эшли башлаган.

Бөек Ватан сугышы елларының искиткеч авыр шартларында да Китап палатасы эшчәнлеген туктатмаган. Фашист илбасарларын җиңгәннән соң, палатаның эше җайга салына, библиографик күрсәткечләр чыгару тәртипкә китерелә. Вакытлы матбугат, ноталы басмалар, рецензияләрнең аерым елъязмалары, 1961 елдан Татарстан АССРның Республика китапханәсе (хәзерге

Милли китапханә) белән берлектә «Татарстан Республикасы башка республикалар матбугатында» дигән библиографик күрсәткечләр әзерләп чыгарыла. Аерым чыккан елъязмалар шул ук 1961 елда, берләштерелеп, «Матбугат елъязмасы» исеме белән дөнья күрә башлый. Бу белешмәне чыгару хәзер дә дәвам итә.

Китап палатасының эше елдан-ел камилләшә бара, библиографик белешмәләрнең яңа төрләре төзелеп бастырыла. Татарстанда басылып чыккан татар китапларының тулы библиографик «Татарстан китаплары» күрсәткече хәзерләнә һәм 1979–2010 елларда аның 6 томы нәшер ителә.

2007 елның гыйнварында Китап палатасының исеме һәм статусы үзгәртелеп, ул, Дәүләт матбугат архивы буларак, Татарстан Баш архив идарәсе карамагына күчерелде. Анда елына 25 меңләп басма берәмлек кабул ителә. Хәзерге вакытта Татарстан Китап палатасы фондында 1 миллион 800 меңнән артык берәмлек басма продукция саклана.

Чит илләрдә татар китабы

Татар кешесе элек-электән, кайда гына йөрсә дә, китаптан аерылмаган һәм гыйлемгә омтылышын өзмәгән. Язмыш җилләре газиз Ватаныннан, туган җирләреннән читтә йөрткәндә дә, ул китапка үрелгән. Чөнки илдән читтә вакытта китап аның иң якын киңәшчесе дә, сердәше дә, юанычы да, күңел шифасы да булган.

Татар китабының чит илләрдәге эзләренә бәйле кайбер мисалларга тукталабыз.

Мәшһүр татар сәяхәтчесе, дини, иҗтимагый һәм сәяси эшлекле, үткен публицист, нашир һәм журналист Габдерәшит Ибраһимов 1895 елда Төркиядә, Истанбул шәһәрендә, «Чубан йылдызы» китабын бастырып тараткан. Бу китапта Россия мөселманнарының кыскача тарихы һәм шул чордагы хәлләре тасвирланган. Автор элекке татар ханлыкларында ислам диненең таралуы турында язган, патша хөкүмәтенең көчләп христианлаштыру һәм руслаштыру сәясәтен тәнкыйтьләгән. Диния нәзарәтенең эшчәнлеге һәм эчке төзелеше белән таныштырып, аның, мөселманнар мәнфәгатенә хезмәт итүгә караганда, империячел хакимият кулындагы күндәм бер коралга әверелүен фаш иткән. Патша хөкүмәтенә кискен каршы эчтәлектәге, татарларны һәм, гомумән, мөселманнарны дини-милли азатлыкка өндәгән бу китапны Россиягә кертү тыелган. Әмма Габдерәшит Ибраһимов әсәре төрле яшерен юллар белән ватандашларына килеп ирешкән. Әлеге китапны, әлбәттә, Россиядәге рәхимсез цензура шартларында бастыру мөмкин булмаган. Шуңа күрә милләте һәм диндәшләре өчен янып көйгән укымышлының бу хезмәте Төркиядә нәшер ителгән. Шулай да автор бу китабын, Россиядә цензура бетеп торудан файдаланып, 1907 елда Петербургта кабат бастырган.

Габдерәшит Ибраһимовның «Чубан йылдызы» китабы тарихчылар тарафыннан милләтебездә хөр фикер уянуга сәбәп булган 3 китапның берсе дип бәяләнде. Ягъни тагын икесе: Ш. Мәржанинең «Мөстәфадел-әхбар...» хезмәте һәм Г. Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәре.

Россия төрле илләр белән алып барган сугышларда катнашкан татар солдатлары да үзләре белән китап йөрткәннәр. Гайре табигый сугыш һәм окоп шартларында да татар хәрбиләре кулга китап алыр җай тапканнар, аны күз карасыдай саклаганнар. Хәтта әсирлектә газап чиккәндә дә татар әсирләре, мөмкинлек булганда, китаптан аерылмаганнар. Мәсәлән, 1904–1905 еллардагы рус-япон сугышында катнашкан һәм әсирлектә булып кайткан Габделхаликъ Әхмировның «Япон мөхарәбәсе, яхуд Татар солдаты» китабында (1909) бу турыда кызыклы мәгълүматлар бар. Ул Япониянең Аскафур шәһәрендә үзләре сак астында тотылган урында 650 мөселман әсире булганын яза. Алар шунда да белемнәрен тирәнәйтергә тырышканнар. Үзләрендә Коръән, берничә шәригать китабы, Әхмәтһади Максудиның «Гыйбадәте исламия» һәм дин нигезләрен өйрәтә торган тагын берничә китап, санаулы гына хикәя китаплары булган. Әсирләр, үзара акча җыеп, циклостиль сатып алганнар һәм китапларын башта 100–150 данә, аннан соң, ихтыяҗ тугач, тагын кирәкле микъдарда бастырып күбәйткәннәр. Японнар татарларның тырышлыгын күреп сокланганнар, аларны хуплаганнар.

